ЧЫГЫМЛЫ ЯЛ

Чит ил кояшы астындамы, әллә инде үзебезнеке дә ярыймы?

> 5

ӘШЕМ КЕШЕСЕ

Йорттагы тузанны кем сөртергә тиеш тә, чүкеч кем кулында?

> 16

АЙДАР ҖАББАРОВ:

«Бүгенге татар театры тамашачысы мәгънәле спектакльләргә сусаган»

> 18

ВАТАНЫМ ТАТАРСТАН

1918 елның 12 мартыннан бирле чыга | ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ ГОМУМТАТАР ГАЗЕТАСЫ | № 33 (29000) | Җомга | 10 март | 2023 ел

Газета 1968 елда Хезмәт Кызыл Байрагы ордены белән бүләкләнде

www.vatantat.ru /vatanimtatarstan /t.me/vatantat

4604609 000131

«ВТ» архивыннан

БЕЗГӘ ДИГӘН КЫЗ ТУМАГАН!

АВЫЛЛАРДА КӘЛӘШЛӘР ҖИТМИ

Үскән бере китеп бара – авыл кызларга мохтаҗ. Заманында бик популяр булган бер җыр сүзләрен кабат көйләп йөри башламаек. Татарстан авылларында өйләнергә кеше җитми – кәләшләр аз, ди бит статистика. Ил язмышы хатын-кыз язмышына бәйле булуына кабат инанасың инде шуннан. Гүзәл затлар кияүгә чыкмагач, яңа гаиләләр барлыкка килмәгәч, балалар тумагач, авыл киләчәге турында да борчыла башламый хәл юк...

> 7

Ишетми калмагыз

Татарстан Рәисе Рөстәм Миңнеханов иң алдынгы өч төбәк җитәкчесе арасына кергән. Сәяси һәм икътисадый тикшеренүләр агентлыгы белгечләре чыгарган нәтиҗәне «Известия» җиткерде. Беренче урында – Мәскәү мэры Сергей Собянин, Чечня башлыгы Рамзан Кадыйров исемлектә икенче урында урнашкан. Белгечләр фикеренчә, Рөстәм Миңнеханов коммуналь челтәрләрне яңарту программасын тормышка ашыру, шулай ук 2024 елда Казанда «Киләчәк уеннары»на әзерләнү нәтиҗәсендә шулай югары күтәрелгән. Беренче ун җитәкче арасында Александр Беглов (Санкт-Петербург), Дмитрий Азаров (Самара), Алексей Дюмин (Тула), Александр Моор (Төмән), Андрей Воробьев (Мәскәү өлкәсе), Андрей Никитин (Түбән Новгород) һәм Вячеслав Гладков (Белгород) та бар.

Быел республикада юл эшләре программасы буенча 48,5 миллиард сум акча тоту каралган. Шуның 32,4 миллиард сумы – төбәк бюджетыннан, 16,1 миллиарды федераль бюджеттан юлланачак. Бу хакта Татарстанның транспорт һәм юл хуҗалыгы министры урынбасары Артем Чукин «Татар-информ»га әйткән.
Артем Чукин сүзләренә караганда, республикада юл эшләре программасы буенча бер ел эчендә 27,1 чакрым озынлыкта төбәк юллары салыначак, 300 чакрым чамасы озынлыктагы автомобиль юллары төзекләндереләчәк, 400 чакрым озынлыктагы җирле юллар тәртипкә китереләчәк.

Гыйнвар – февраль айларында Татарстан юлларында балалар катнашында килеп чыккан аварияләр, аларда һәлак булучылар һәм зыян күрүчеләр саны арткан. Татарстан буенча Эчке эшләр министрлыгының Дәүләт автомобиль инспекциясе идарәсе башлыгы Рөстәм Гарипов әйтүенчә, быелның ике аенда республика юлларында 44 шундый очрак теркәлгән. Бу – узган елның шушы ук чорындагыга караганда 7гә күбрәк. 3 баланың гомере өзелгән (былтыр икәү булган). 49ы җәрәхәтләнгән яки имгәнгән (2022 елның гыйнвар – февраль чорындагы белән чагыштырганда 11 кешегә артыграк).
Гомумән, ике ай эчендә республика юлларында 434 авария килеп чыккан. Узган елның шул ук чоры белән чагыштырганда 14 очракка күбрәк бу. 39 кеше һәлак булган. 559 юлчы җәрәхәтләнгән яки имгәнгән.

Татарстанда ял көннәрендә көчле җил, карлы яңгыр көтелә.
Гидрометеоүзәк хәбәр иткәнчә, шимбә – 11 мартта төнге сәгатьләрдә карлы яңгыр, кыска вакытлы буран булачак. Көндез явым-төшем туктый. Җил, юнәлешен үзгәртеп, төньяктан исә башлаячак. Көндез –1...–6, төнлә –3...–8 градус. Юлларда – көчле бозлавык.
Якшәмбе – 12 мартта көндез көнбатыш районнарда секундына 15–18 метр тизлектә көчле җил, юеш кар, яңгыр булырга мөмкин. Көндез җылыта: +1...+6 градус. Төнге сәгатьләрдә һава температурасы –3...–8 градус чикләрендә тирбәләчәк.

Районнарда ни хәлләр?

Мамадыш

Хәзерге вакытта Татарстанның югары уку йортларында Мамадыш районыннан максатчан белем бирү программасы буенча 74 студент белем ала. Диплом алганнан соң, алар туган якларына кайтып, белгечлеге буенча эшкә урнашачак. Әйтик, 2023 елда Мамадышка 8 яшь укытучы кайтачак, тагын 14 булачак белгеч хәзерге вакытта өченче һәм дүртенче курсларда белем ала. Моннан тыш, бу елдан район хастаханәсендә дә 4 яшь ак халатлы белгеч эшли башлар дип көтелә. Якын киләчәктә табиблар сафын тагын 22 белгеч тулыландырачак. Хәзерге вакытта аграр вузларда районнан 12 студент югары белем ала. Аларның икесе бу җәйдә үк Мамадышка кайтачак.
(«Нократ»)

Әлки

Үргәагар авылы мәчетендә ремонт эшләре тәгәлләнде, яңа манара да куйдылар. Мәчеттә вәгазь сөйләделәр, күмәк намаз укыдылар. Мәчет эченнән дә, тышыннан да бик матур, затлы итеп эшләнгән. Манара да, мәчет тә яшел утлар белән яктыртыла. Бөтен авылга нур чәчеп торган мәчеткә авыл кешеләре, тирә-күрше авыллардан да кунаклар байтак җыелган иде. Үргәагар авыл җирлеге башлыгы Әнвәр Рәхимҗанов Буа районы төзүчеләренә, Базарлы Матак осталарына олы рәхмәтен җиткерде, истәлеккә бүләкләр тапшырды. Корбан хәзрәт Фәхриев төзелеш материалларын сатып алуда, осталарны ашатуда ярдәм иткән авылдашларга изге теләкләр теләп, рәхмәтләрен белдерде. Район мөхтәсибе Ирек Сәлахиев сүзләренчә, әлеге эштә, зурмы-кечкенәме өлешен керткән һәр кешегә Аллаһының рәхмәте булыр.
(«Әлки хәбәрләре»)

Кама Тамагы

Район башлыгы Наил Вазыйхов ике яшь гаиләгә – Гыйззетдиновлар һәм Мәһдиевләргә торак сатып алу яки шәхси торак төзелеше өчен социаль түләү алу хокукы бирелү турында таныклыклар тапшырды. «Ирем Рафил хәзерге вакытта махсус хәрби операция зонасында хезмәт итә, – диде Ләйсән Мәһдиева. – Әлегә әти-әниебез белән яшибез. Быел үз йортыбызны төзергә планлаштырабыз һәм сертификат акчасын әлеге максатларда кулланырга уйлыйбыз».
(«Идел таңнары»)

Зәй

«Татнефтедор» автомобиль юллары идарәсенең Зәй филиалы башлыгы Фидаил Хәернасов өченче мәртәбә махсус хәрби операциядә катнашучы егетләр янында булып кайтты. Аның улы хәрби операциянең беренче көннәреннән Ватанны саклый. Әлеге предприятиедән мобилизация буенча чакырылган егетләр дә бар. Алар белән элемтә өзелми, гаиләләренә даими ярдәм күрсәтелә. «Егетләрнең кәефләре хәрбиләрчә. Әзерлекләре яхшы, һәркайсы нинди эш белән шөгыльләнергә тиеш булуын яхшы белә. Андагы егетләрнең дуслыгына сокланырлык», – дип сөйләде ул.
(«Зәй яңалыклары»)

РӘХМӘТ, УКЫТУЧЫ!

Татарстан Рәисе Рөстәм Миңнеханов 8 Март бәйрәме алдыннан Казан Кремлендә Татарстан педагогларына һәм остазларына дәүләт бүләкләре тапшырды.

«Сезне чын күңелдән якынлашып килүче яз, матурлык һәм мәхәббәт бәйрәме – Халыкара хатын-кызлар көне белән котлыйм. Табигать хатын-кызларга матурлык һәм бетмәс энергия, наз һәм тугрылык, тормыш зирәклеге, гаҗәеп көч һәм сабырлык биргән. Сез гаилә учагын саклыйсыз һәм һөнәри эшчәнлегегездә уңышларга ирешәсез», – диде Рөстәм Миңнеханов.

Ул билгеләп үткәнчә, бүген яшь буынны тәрбияләү һәм үстерүнең әһәмияте тагын да арта. Нәкъ менә шуңа күрә Россия Президенты Владимир Путин 2023 елны Педагог һәм остаз елы дип игълан итте.

«Һәрберебезнең тормышында балалар бакчасында – безнең өчен иң яхшы тәрбияче, мәктәптә, һөнәри белем бирү учреждениесендә – укытучы, эштә остаз бар иде. Аерым, җылы хисләр ул. Ике яклы булгандыр дип ышанам. Сезгә тынгысыз хезмәтегез өчен рәхмәт белдерәсем килә», – диде Рөстәм Миңнеханов.

tatarstan.ru

Рөстәм Миңнеханов ветеран-укытучы, тыл хезмәтчәне Нурания Мөхәммәт кызы Газиевага 100 яшьлек юбилее белән котлады һәм аңа «ТАССРның 100 еллыгы» медален тапшырды. Юбиляр Түбән өлкәсенең Түбән Тәүде районындагы Киндер авылында туган. 1961 елда Алабуга дәүләт педагогия институтын тәмамлый, гомере буе төрле уку йортларында – башта Түбән өлкәсендә, ә 1971 елдан Казанда татар теле һәм әдәбияты укытучысы булып эшли. 58 ел дәвамында балаларга белем бирә.

СЕЗ – БЕЗНЕҢ ТАЯНЫЧ

tatarstan.ru

Иң матурлары, иң акыллылары, иң булганнары. Дәүләт Советы Рәисе Фәрит Мөхәммәтшин республика хатын-кызлары турында шулай диде. Бәйрәм алдыннан, матур гадәт буенча, Казанда «Ел хатын-кызы. Ел ир-аты: хатын-кыз карашы» бәйгесе җиңүчеләрен бүләкләделәр.

Бүләкләү тантанасына килгән хатын-кызларны Татарстан Рәисе Рөстәм Миңнеханов исеменнән парламент башлыгы Фәрит Мөхәммәтшин тәбрикләде.

– Әлеге бәйге ярдәмендә без ел саен үз эшендә югары профессионаллар, олы хөрмәткә лаек әниләр, искиткеч хатын-кызлар белән танышабыз. Аларның тормышлары республикабыз язмышына тыгыз бәйләнгән. Чөнки бу хатын-кызлар Татарстанның икътисадый, интеллектуаль һәм рухи-мәдәни үсешен билгели, – диелә Рөстәм Миңнехановның сәламләү хатында. – Бүгенге катлаулы чорда безнең хатын-кызлар ирләре, абыйлары, әтиләре белән беррәттән Ватан иминлеге турында кайгырта. Бу – фидакарь хезмәт, ихтыяр көче һәм рухи юмартлыкның лаеклы үрнәкләре. 80 ел чамасы элек әниләре һәм әбиләре эшләгән кебек үк, хәзерге хатын-кызлар ныклы тыл, ышанычлы ярдәм, йорт һәм туганнары белән өзелмәс элемтә булдыру, туган илнең тыныч һәм имин киләчәге өчен кулдан килгәннең барысын да эшли.

Эштә дә, гаиләдә дә, тылны саклауда да, балаларны тәрбияләүдә дә иң яхшылары. Фәрит Мөхәммәтшин республика хатын-кызлары турында шулай диде:

– Тормышымны хатын-кызлардан башка күз алдына китерә алмыйм. Сез гаилә традицияләрен, ватанпәрвәрлекне кадерләп саклыйсыз һәм киләсе буыннарга тапшырасыз. Шунысы да куанычлы: гүзәл затларыбыз республикабызның күп кенә башлангычларында актив катнаша. Икътисад һәм сәясәт, сәламәтлек саклау һәм мәгариф, фән һәм мәдәният – тормышыбызның бу һәм башка күп өлкәләрен сезнең талантыгыздан һәм һөнәри осталыгыгыздан башка күз алдына да китереп булмый. Без Татарстан хатын-кызлары белән горурланабыз, – диде парламент башлыгы. – Сездә без ир-атларда булмаган энкерсезлек, җайга сала белү, һәркемгә яраклы чишелеш таба белү бар. Сез – безнең таянычыбыз.

Тантанада хатын-кызларның гаилә учагын саклаучылар гына түгел, ә һөнәри эшчәнлектә, җәмгыять тормышының барлык тармакларында да югары нәтиҗәләргә ирешә алуларын кат-кат әйттеләр. Бәйгедә җиңүчеләр арасында күпбалалы әниләр, гаиләләрендә 8әр бала алган хатын-кызлар, шәфкать туташлары, табиблар, сәнгать эшлеклеләре, эшмәкәрләр, укытучылар, технологлар, галимнәр һ.б. бар иде. Конкурска Татарстанның барлык районнарыннан диярлек 300дән артык гариза килгән. Җиңүчеләрне 10 номинация буенча бүләкләделәр.

Оештыручылар белдергәнчә, иң күп җиңүчеләр гадәттәгечә «Хатын-кыз – ана» номинациясендә билгеләнгән. Алар арасында Азнакай районының Әсәй авылыннан Резеда Хәмидуллина да бар. Биш бала анасы, офицер хатыны, ирен һәм өлкән улын махсус хәрби операциягә озатып, зур терлекчелек хуҗалыгын җитәкли. «Хатын-кыз – ана» номинациясендә тагын бер җиңүче – фронтка ярдәм итү өчен хәрби хезмәткәрләрнең хатыннарын берләштергән Зәй районыннан алты бала әнисе Елена Терентьева. Тукай районының Круглое Поле бистәсе мәктәбендә физика укытучысы, ике бала әнисе һәм биш баланы тәрбиягә алган Светлана Рогова һәм башкалар да – шул исемлектә.

Моннан тыш, гүзәл затларны «Хатын-кыз – мәдәният һәм рухият», «Хатын-кыз – үрнәк», «Хатын-кыз – галим», «Хатын-кыз – бизнес-леди», өлкәннәр өчен «Өченче буын героинясы», «Хатын-кыз – лидер», «Минем язмышым – минем һөнәрем» номинацияләрендә бүләкләделәр. Бәйгедә ир-егетләрне дә онытмадылар. Аларны «Ир-ат – лидер», «Ир-ат – игелекле йөрәк» номинацияләрендә бүләкләделәр. «Ир-ат – лидер» булып Татарстан вице-премьеры Евгений Варакин, Татарстанның чаңгы белән трамплиннан сикерү федерациясе президенты Әнәс Вәлиев, Тәтештәге балалар сәнгать мәктәбе директоры Сергей Арцыбашев танылды. Изге эшләре өчен Мамадыштан Фәнил Гыйззәтуллин, Бөгелмәдән Альберт Кәримов, Теләчедән Рәис Нуретдинов билгеләп үтелде.

Ләйсән САФИНА

СОРАГАНГА БИРӘЛӘР

Мамадышта тау чаңгысы паркы төзеләчәк, ә Алабугада Шишкин буаларын танымаслык булып үзгәртмәкчеләр. Татарстан Министрлар Кабинетында узган брифингта Кече шәһәрләр һәм тарихи җирлекләр илкүләм бәйгесенең узган елгы җиңүчеләре һәм быел федераль үзәктән грант отарга дәгъва кылучылар турында сөйләделәр. Агымдагы елда кайсы районнарга уңыш елмаячак?

«Татар-информ»

Тәүге тапкыр тарихи шәһәр буларак Зөя шәһәр-утравын да бәйгегә тәкъдим иттеләр.

Быел республикада төзекләндерү, коммуналь челтәрләрне яңарту, капиталь ремонт һәм төзелешкә бәйле барлыгы 44 республика программасы гамәлдә. Алар кысасында 51,7 миллиард сумлык эш башкарылачак дип фаразлана. Боларга өстәп, 6 илкүләм проект һәм 4 дәүләт программасы да эшли. Аларның гомуми бәясе 15 миллиард сумга якын тәшкил итә.

– Гадәттәгечә иҗтимагый киңлекләрне һәм ишегалларын төзекләндерүгә бәйле программаларга зур урын бирелә, – диде Татарстан төзелеш, архитектура һәм ТКХ министры Марат Айзатуллин. – Быел 960 ишегалды территориясе, 68 парк, сквер һәм яр буе тәртипкә китереләчәк. Алар арасына «Торак һәм шәһәр мохите» илкүләм проекты кысасында үткәрелүче Кече шәһәрләр һәм тарихи җирлекләр бәйгесенең республикадагы җиңүчеләре дә керә.

Билгеле булганча, әлеге бәйге Россия Президенты Владимир Путин кушуы буенча оештырылды һәм тәүге тапкыр 2018 елда узды. Моңарчы анда халык саны 100 мең кешедән артмаган федераль һәм төбәк әһәмиятендәге кече шәһәрләр һәм тарихи җирлекләр генә катнашса, былтыр мондый мөмкинлекне 200 меңгә кадәр кеше яшәүче шәһәрләргә дә бирделәр.

– Татарстанның иҗтимагый киңлекләрне үстерү юнәлешендә шактый тәҗрибәсе бар. Без республикада бу эш белән 2015 елдан бирле шөгыльләнәбез. Моның нәтиҗәсе буларак, бәйге башланганнан бирле 40 проект федераль үзәктән грант алды инде. Аларның гомуми күләме 2 миллиард 700 миллион сумга җитте, – диде министр.

Узган ел, мәсәлән, җиңүчеләр исемлегендә 8 республика проекты бар. Алдагы еллардан аермалы буларак, былтыр бәйгене бер ел эчендә ике тапкыр үткәргәннәр. Җәй көне үткәрелгән конкурста республикадан юлланган 7 проектның алтысы (Болгар, Алабуга, Зәй, Яшел Үзән, Лаеш һәм Лениногорск шәһәрләрендә иҗтимагый киңлекләрне төзекләндерүгә бәйле эшләр) жюри әгъзалары тарафыннан хупланса, кыш көне Татарстаннан тәкъдим ителгән Яшел Үзән һәм Әлмәттәге ике проект та җиңүчеләр исемлегенә эләккән. Барлык проектларны тормышка ашыру өчен 696 миллион сум грант бүлеп биреләчәк. Моннан тыш, республика бюджетыннан да ярдәм каралган. Проектларны киләсе ел азагына кадәр тормышка ашырып бетерү каралган.

Аерым алганда, Мамадышта экстремаль һәм кышкы спорт төрләре паркы төзеләчәк. Моның өчен федераль, республика һәм җирле бюджеттан 130 миллион сумга якын акча бүлеп биреләчәк. Зәйнең Җиңү проспектында Яшьләр паркы барлыкка киләчәк. Проектны тормышка ашыру өчен федераль бюджеттан гына да 85 миллион сумлык грант алачаклар. Ә менә Алабугада Шишкин буалары танымаслык булып үзгәрәчәк.

Илкүләм бәйгенең быелгы катнашучылары да билгеле. Алар турында Татарстан шәһәрләрен үстерү институты директоры Наилә Зиннәтуллина сөйләде.

– Катнашучыларны берничә этаптан торган сайлап алу барышында билгеләдек. Болар – халык саны 20 мең кешедән артмаган кечкенә шәһәрләр арасында – Минзәлә һәм Тәтеш, халык саны 20–50 мең кеше тәшкил иткән кечкенә шәһәрләр арасында – Азнакай, Баулы, Нурлат һәм Менделеевск, 50–100 мең кеше яшәүче кечкенә шәһәрләр арасында исә Бөгелмә җиңү өчен көч сынашачак. Без алырга мөмкин булган грантның гомуми күләме 675 миллион сум тәшкил итә, – диде Наилә Зиннәтуллина.

2020 елдан бирле төзекләндереләчәк иҗтимагый киңлекләрне сайлап алуда халык та катнаша. Моның өчен онлайн рәвештә тавыш бирү дә җитә. Былтыр, мәсәлән, бу эштә 207 меңнән артык кеше катнашкан. Быел онлайн тавыш бирү 15 апрельдән алып 31 майга кадәр Татарстан Дәүләт хезмәтләре порталы һәм кесә телефонындагы «Услуги РТ» кушымтасы аша үткәреләчәк. 14 яшьтән өлкәнрәк һәркем теге яки бу иҗтимагый киңлек өчен тавыш бирә алачак, дип искәрттеләр брифингта. Иң күп тавыш җыйган катнашучылар киләсе елда төзекләндереләчәк җирлекләр исемлегенә эләгәчәк.

Эльвира ВӘЛИЕВА

КАБЫЗГАНЧЫ САНЫЙСЫ

Татарстанда айлык уртача хезмәт хакына 972 литр бензин сатып алып була. Сүз рульдә йөрүчеләр ешрак өстенлек биргән АИ-92 маркалы ягулык турында бара. Белгечләр ил күләмендә халыкның кесә ягын һәм бензин бәяләрен чагыштырган. Нәтиҗәдә Татарстан рейтингның 31 нче баскычында урнашкан. Кайсы төбәкләрдә яшәүчеләргә акча янчыгын кысыбрак тотарга?

Бензин, барыннан да бигрәк, Ямал-Ненец автономияле округы, Мәскәү һәм Чукоткада яшәүчеләргә арзанракка төшә. Росстат мәгълүматларына нигезләнеп, «РИА-Рейтинг» агентлыгы үткәргән тикшерү әнә шуны сөйли. Саннардан күренгәнчә, ил күләмендә бензин бәяләре узган ел башыннан бирле тотрыклы саклана. 2022 елның март – июнь айларында ягулык чагыштырмача арзанайган да әле. Ел дәвамында бензин бәясе 0,9 процентка кимегән, ди белгечләр. Якын арада ул әллә ни кыйммәтләнмәячәк, дип тә тынычландырганнар руль артындагыларны. Ник дисәң, билгеле хәлләр аркасында, нефть продуктларын читкә чыгару күрсәткече кимеде. Шуңа күрә ил базарында чимал күп.

Ничек кенә булмасын, ил төбәкләре арасында да бензин бәясе шактый аерыла. Чиләбедә, мәсәлән, 92ле бензинның бер литры 43 сум тирәсе торса, Чукоткада ул – 63 сум. Ил күләмендә әлеге төр ягулыкның бер литры уртача 47 сум 18 тиен тора. Тик алтын чыгаручылар төбәге булган Чукотка белән шул ук Чиләбе халкының янчыктагы акчасы да – җир белән күк арасы. Мәгълүмат өчен генә булса да әйтик: Чукоткада уртача хезмәт хакы 99 мең 984 сум тәшкил итә.

Шуңа күрә дә айлык уртача хезмәт хакын төбәкләрдәге бензин бәяләре белән чагыштырганнар. Ягулыкның машина йөртүчеләр күбрәк сатып алган 92ле маркасын сайлап алганнар. Югарыда әйтелгәнчә, Ямал-Ненец автономияле округында яшәүчеләргә ягулык салу станциясендә акча җитәрме дип борчыласы юк. Анда уртача хезмәт хакына якынча 2 мең 600 литр бензин сатып алырга мөмкин. Мәскәүдә әлеге күрсәткеч – 1 мең 300 литр, ил күләмендә исә 1 мең 200 литр тәшкил итә. Россиядәге 89 төбәкнең (яңа төбәкләрдәге күрсәткечләр исәпкә алынмаган. – **Ред.**) 16сында айлык уртача хезмәт хакына 1–1,5 мең литр ягулык килә, ди белгечләр. Татарстанда исә рульдәгеләр айлык акчасына уртача 972 литр бензин салып йөри ала. Мәсәлән, Чувашиядә әлеге күрсәткеч – 758, Башкортстанда – 884, Самарада 901не тәшкил итә. Татарстан илкүләм рейтингның 31 нче баскычында тора. Исемлектәге күршеләребез – Новосибирск һәм Еврей автономияле өлкәләре.

Ингушетия, Чечня, Кабарда-Балкар республикаларында исә «тимер ат»та элдергәнче, җәяү йөрүең хәерлерәк. Чөнки кесәдәге акча барыбер озакка җитмәячәк. Ингушетия рейтингның иң соңгы баскычына эләккән әнә. Анда айлык уртача хезмәт хакына күп дигәндә 586 литр бензин алып була. Илнең сигез төбәгендә әлеге күрсәткеч 700 литрдан кимрәк икән.

Татарстанда ягулык-энергетика ресурсларын сак куллану һәм аның сыйфатын тәэмин итү идарәсе мәгълүматларына караганда, республика ягулык салу станцияләрендә бер литр 92ле бензин бәясе 40 сум 90 тиен – 46 сум тирәсендә тирбәлә. Ә 95ле ягулык өчен күп дигәндә 49 сум 80 тиен түлисе.

Идел буе федераль округында АИ-92 маркалы бензинны ваклап сатуга иң югары бәяләр



- Киров өлкәсе – 45 сум
- Самара өлкәсе – 45 сум 85 тиен
- **Татарстан Республикасы – 46 сум**
- Мари Иле Республикасы – 46 сум 20 тиен
- Ульян өлкәсе – 46 сум 30 тиен
- Башкортстан Республикасы – 46 сум 35 тиен
- Чувашия Республикасы – 46 сум 70 тиен
- Мордовия Республикасы – 46 сум 70 тиен
- Оренбург өлкәсе – 46 сум 70 тиен
- Удмуртия Республикасы – 46 сум 75 тиен
- Пенза өлкәсе – 46 сум 80 тиен
- Пермь крае – 47 сум 10 тиен
- Саратов өлкәсе – 47 сум 15 тиен
- Түбән Новгород өлкәсе – 47 сум 15 тиен

(2023 елның 7 мартына алынган мәгълүматлар)

Язучы фикере

КҮРЕНМИ ТОРГАН ХАТЫН

Марат КӘБИРОВ

Гайре табигый хәлләр турындагы әсәрләрем хәтсез генә булгач, адым саен диярлек бер үк төрле сорау бирәләр: «Сез мистикага ышанасызмы?» Мин баш чайкыйм. Ә фантастикага? Ә аномаль күренешләргә? Ә убырларга? Шайтаннарга? Күзгә күренми торган кешеләргә? Баш чайкауның гына ярдәме тимәгәч, кистереп әйтергә мәҗбүр булам: «Юк, ышанмыйм». Алар шикләнәләр: «Үзегез ышанмагач, ничек шундый сәер хәлләр турында язып була соң ул?» – диләр. Хәзер инде мин үземнең ышанмавыма үзем дә шикләнә башлыйм…

Ә бер карасаң, гайре табигый хәлләрнең барысы да диярлек – чынбарлыкның бер өлеше. Тормыш ул безнең күз карашы җиткән нәрсәләр белән генә чикләнми, без бары тик үз мөмкинлекләребез ирек биргән кадәр генә күрә алабыз, ә тормыш чүт кенә киңрәк тә, катлаулырак та. Шуңа күз нурыбыз күләгәсенә эләккән өлешләре бездән читтәрәк кала. Мин, мәсәлән, күзгә күренми торган кеше барлыгын төгәл беләм. Һәм ул ханым безнең оешмада эшли. Сезнекендә дә, бәлки, шундый ук башка кеше бардыр. Сез аны белмисез генәдер, күргәнегез генә юктыр.

Ул эшкә башкалардан күпкә алданрак килә. Кичәгедән калган бөтен чүп-чарны җыештырып чыга. Идәннәрне сөртеп ала. Газета-журналларны алып кереп хезмәткәрләр өстәленә тезеп чыга. Компьютерлар челтәрен куша. Чәй кайната. Шуннан иплән кенә бүтән хезмәткәрләр килә башлый. Кайберләре йокыдан айнып җитә алмаган, кайберләре эш турында уйлана, кайсылары – башка нәрсә хакында. Һәркем үз уйларына бирелеп яши бит инде, үз дөньясында яши. Күзләренә күренмәгәч, аның яныннан исәнләшми генә узып китәләр. Ул моңа игътибар итми, үзенең кем икәнен яхшы белә, башлап эндәшми.

Эш барышында да ул бер өстәлдән икенчесенә йөгереп кенә тора, кәгазьләр китерә, алып китә. Чүп савытлары тулса, аларны җыештырып ала, идәннәрне юып чыга. Хезмәткәрләр чәй яки каһвә эчәргә теләсә дип су кайнатып куя. Ә алар эчәргә тели. Кайчагында түгеп-чылатып та китәләр, кайвакыт кулларындагы чынаякны төшереп ваталар да. Ул дәшми-тынмый гына чистартып куя. Берәрсенең туган көне яки берәр төрле бәйрәме булса, хезмәткәрләр җыйнаулашып бәйрәм итә. Ә ул ханым һәр эштә ярдәмләшеп йөри, артларыннан җыештырып куя. Үзен табынга чакырмыйлар, тәмлүшкәләр белән сыйламыйлар, хәтта сыңар торт кисәге дә алып бирмиләр. Чөнки ул – күзгә күренми торган.

Мактаулы исемнәре, фәнни яки һөнәри дәрәҗәләре юк. Бүтәннәргә, фәлән ел безнең оешмада эшләде дип булса да, төрле титуллар тагалар, бүләкләр бирәләр. Аңа бернәрсә дә тәтеми. Моннан әллә ничә дистә ел элек билгеләнгән хезмәт хакына беркайчан да бернинди өстәлмә дә алганы юк аның. Хәзер хезмәт хакын да кул куеп алмалы түгел, банк картасына гына күчерәләр. Сәер инде шундый… Хәтта хезмәт хакы да күзгә күренми торган нәрсәгә әверелеп килә. Кулга тими, күзгә күренми, алу белән тарала да бетә…

Аның күзгә күренми торган кеше икәнен башта ире сизде бугай. Иртән торуына ашарына әзер, киемнәре пөхтә, өйдә тәртип… Ә хатыны күренми… Кич кайтуына да бөтен нәрсә әзер… Ә хатыны… Ире шул могҗизага беркадәр албырап йөрде дә, барсын да аңлап алгач, күзгә күренә торган бер яшь хатынга барып йортка керде. Ни дип әйтсәң инде…

Хәзер балалары сизә… Ашарларына әзер, өс-башлары каралган, өйләрендә тәртип… Алар моны йорт иясе эшли дип уйлыйлар. Шуңа көндезләрен аның белән сөйләшергә тырышып карыйлар. Хәтта кайчакларда өйнең берәр почмагына кәнфит я торт кисәге куеп, аны сыйларга тырышалар. Йорт иясе генә күзләренә күренми. Тик ул барысын да сизеп тора, аларның бу гамәлен хуплый бугай, чөнки төннәрен яннарына килеп башларыннан сыйпый, үбеп ала, һич югында юрганнарын төзәтеп китә. Йокы баскан чак булгач, күзләрен ачалмыйлар, шуңа аны күргәннәре юк. Бары тик тоялар гына…

Моның бик дөрес түгеллеген үзе чамалый инде ул. Балалары үсеп җиткәч, танымыйча куып чыгармаслар микән, дип тә шүрли. «Нинди хатын син? Монда нишләп йөрисең? Әни? Ник моңарчы күзгә күренмәдең?» – дип әйтсәләр дә, берни кылып булмый. Алар хаклы.

Тик ул бернәрсә дә үзгәртә алмый. Дөньяны сөйрәп бару, балаларын аякка бастыру өчен шулай кирәк. Бүтән чарасы юк. Галим булырлык акыл иясе дә түгел. Талант иясе дә. Хәтта урлашу, алдашу, хәрәмләшү, әрсезләнү сәләтләреннән дә мәхрүм. Заман аның үзен дә, эш-гамәлләрен дә дөньяга, кешеләргә күрсәтмәскә тырыша. Хәтта балаларына да. Ул – күзгә күренми торган хатын.

Сине күрмәсеннәр өчен бернинди дә могҗиза кирәкми, гади һәм гадәти булу да җитә. Бүтәннәрнең (ил-дәүләтнең, хәтта дәверләрнең) сине күрмәве дә гайре табигыйлеккә дәлил түгел – сәбәп үзеңдәме, әллә башкаларның күзендәме әле? Кайберәүләр хәтта баш очындагы кояшны да күрми, бар яктылык үзләреннән тарала дип уйлый. Аяк астындагы алтынны да… Без кемнедер, нәрсәнедер күрмибез икән, бу аларның юклыгын аңлатмый әле.

Ә сез мистика дисез…

АКЧА БЕЗДӘ БЕР БУКЧА

Кайвакыт укучылар сорау бирә: «Ни өчен «җәһәннәм санкцияләре» кертелүгә карамастан, Россия икътисады тотрыклы калды? Безнең матди хәлебез алай бик начараймады бит», – диләр. Әйе, чынлап та, Көнбатыш, Россияне авызлыклыйм дип, күпме генә тырышмасын, үткән ел без яшәгән илнең финанс хәле «кызганыч» дигән сүз белән бәяләрлек булмады.

Хәтта андый чакларда төпкә оча торган рубль курсы да җил-давылларга бирешмәде. Россия бюджеты да баштагы айларда профицитлы булды. Доллар-евро шулкадәр күп булды: аларны куярга урын тапмадык. Юк, сүз безнең кесәләрдәге акча турында түгел, экспортерлар хисабындагы доллар хакында бара. Резервларның яртысы, олигархлар миллиардлары чит илләрдә бикләнүгә карамастан, валюталар кирәгеннән артык иде. Финанс хакимиятләре резерв валюталарын кирәксенмичә, милли валюталар белән сәүдә итәргә тотынды. Нефтьне һинд рупиясеннән елгалар итеп агыздык. Кытай юанен саклык акчага әверелдердек. Укучылар, бәлки, ышанып та бетмәсләр (безне Америка белән сугыш хәлендә дип ышандыралар бит инде), Үзәк банк үткән ел АКШның дәүләт облигацияләренә байтак акча тыкты. ТАСС хәбәре бу. «Россиянең Америка дәүләт кыйммәтле кәгазьләренә тоткан акчасы үткән елның ноябрендә алдагы айга караганда үсте һәм 2,092 миллиард долларга җитте. Бу хакта АКШ Финанс министрлыгы игълан иткән документлар сөйли», – дип быелның 19 гыйнварында шул агентлык хәбәр итә. Без НАТОга каршы сугышабыз дип ярсып-ышанып ятканда, финанс хакимиятләре тыныч кына бер табактан ашыйлар, димәк. Юк, юк, сез уйлый күрмәгез: автор берәүне дә тәнкыйтьләми, дөньяның барышына бераз гаҗәпләнә генә. Уртак табында ризык бүлешү бер дә начар түгел ул. Ай саен әле Америкага, әле Кытайга, әле Һиндстанга миллиардлаган доллар акча өләшүебез үткән ел безнең бик мул тормышта яшәвебезне дәлилли. Әле менә яңа гына төрекләр дә, Мәскәү алар җирендә төзергә теләгән газ саклагычны үз акчасына төзесен, дигән теләк белдерделәр. Һәм төзеләчәк тә.

Андый муллыкка үткән ел нигез бар иде. Россиянең нефть-газ керемнәре 2022 елда рекордлы булды. 2022 елның гыйнвар – февраль айларында углеводородлар акчасы 1 триллион 766 миллиард 200 миллион сум булган. Санкцияләр кертелгәч тә керемнәр кимемәгәндер дип уйлыйм, чөнки бәяләр күтәрелде, нефть-газны Көнбатышта сукрана-сукрана булса да сатып алдылар. Чагыштырып карагыз әле: 2021 елның шул ук чорында керемнәр 1 триллион 35 миллиард 700 миллион сум гына булган. Аерма бик зур бит, әйеме. Акчаның муллыгы шул дәрәҗәгә җитте: без аның белән «дус ил»ләрне коендырдык. Күрәбез: хәтта дошман илләргә дә ай саен байтак тамызганбыз. Хосусый капиталның ташкыннар булып чит илгә агылуын искә алмаганда әле бу. Безнең белгечләр, «удаленка»да эшләп, байтак акчаны Урта Азия республикаларына, Төркиягә күчерделәр. Акчаны Россиядә эшләделәр, тотуын тегендә тоттылар.

Дус илләр дә безне буш итмәде, билгеле. Алар безне «параллель импорт»ка кинәндерделәр. Көнбатыш безгә сатмаган товарларны сатып алдылар да, бәягә бәя өстәп, безгә тондырдылар. Кыргызстан, мәсәлән, фин товарларын көтмәгәндә сигез тапкыр күбрәк сатып ала башлаган. Әрмәнстан, Грузия һәм Казахстанга да фин экспорты берничә тапкыр үскән. Нигездә Россиягә сатарга ярамаган товарларны һәм җиһазларны күпләп сатып алган «дус ил»ләр. Товарлар Россия җирләре аша уза. Фин таможнячылары, алар Кыргызстанга яисә Казахстанга барып ук та тормагандыр, Россиядә генә бушатылгандыр, дип уйлый.

Безнең хәл шуңа күрә үткән ел чит ил машинасында барган кешенеке төсле булды. Машина ватылмаганда, хәлеңнең начараюын бер дә сизмисең. Җырлап кына йөрисең. Проблема ремонт кирәк булгач күзгә килеп кадала. Запчастьлар бар алар, бар. «Соры импорт» бу юлы да ярдәмгә килә. Тик менә бәяләре! Бүген Россиянең автомобиль базары – дөньяда иң кыйммәтлесе. Дилерлар хәзер сан артыннан кумыйлар. Бер машина сатып, элек өчне-дүртне саткан кадәр табыш алып була. Шуңа күрә сан кими, бәяләр арта. Хәзер җиңел генә искесен сатып, яңаны ала алмыйсың инде. Шундый проблемалар белән очрашкан саен «матди хәлебез начараймады бит» дигән сорау үзеннән-үзе төшә дә кала.

Көнбатыш үзенең санкцияләр сәясәтен акрын гына көйли, шомарта. Аларны да аңлап була: «безнең кызыбыз кияү күргәнме» дигән шикелле, мондый зур һәм бай илгә ул дәрәҗәдәге каты чикләүләрне берәүнең дә кертәсе юк иде бит моңарчы. Вашингтонда күпме генә теләсәләр дә, Кытай, Һиндстан кебек гигантларның нәфесен җиңә алмыйлар. Соңгылары «аппетит ашаганда килә» дигән кебек, Россия базарыннан файдаланып максималь табыш алып булганын тиз аңлады. Көндәшләрдән чистарган зур базарда үз товарларын чамасыз кыйммәткә саталар, чималны исә үтә арзанга алалар. Көнбатышта да моңа каршы торып булмасын аңладылар. «Нәрсәнедер җиңә алмасаң, аның белән идарә ит» дигән принцип эшкә җигелде. Чимал сатуны тыймыйлар, «түшәм бәя» генә куялар. Нәтиҗәсен карыйк. Быелның гыйнвар – февраль айларында нефть-газ керемнәре 946 миллиард 700 миллион сум гына. Чимал соңгы биш елда бер тапкыр да бу кадәр аз акча бирмәгән. Саннарны китермим: бюджет дефициты беренче ике айда еллык планны тутыра язды инде. Федераль бюджетны Милли байлык фонды коткара. Ул фондның бер кызык ягы бар: аңа быел беркем дә акча салмады, киресенчә, байтак юаньнарны һәм алтыннарны алдылар гына. Шуңа карамастан фондның сумнардагы күләме үсте! Финанс хакимиятләре валюта курсларын үстерү аша ирешә моңа. Валюта сатылган һәм капчыктагысы кимегән саен сумның курсы түбәнәячәк дигәнне аңлата бу. Рубль курсы түбәнәйгәндә кемнең хәле начарая? Импорт товарларны валютага алабыз, сумнарга сатабыз бит.

Россиянең товар складлары бүген суыткычлар һәм башка көнкүреш техникасы белән тулган. Бердән, дистрибьюторлар, дус илләр дә товар бирүне туктатыр дип курыкканлыктан, язгы якта чамасыз күп техникага заказ биргән. Ихтыяҗ да ул чакта зур булган. Товар ташуга бәйле проблемалар аркасында көнкүреш техникасы складларга әле генә килеп җиткән. Халыкның инде техника сатып алу теләге кимегән, ихтыяҗ юк. Кесәләрдә җилләр уйный, кысып тотарга туры килә.

Доллардан һәм евродан баш тартабыз дип, ат йөреше ясаганда, безнең финансчылар һәм сәүдәгәрләр ялгыш шакмакка килеп төшкән. Хәзер шул аңлашыла. Нефтьне һинд рупияләренә һәм, җитмәсә, арзанга сатып, Россия үзенә зур проблема тудырды. «Кара алтын» сатып алган рупияләрне куярга урын юк. Һинд регуляторы (Үзәк банкы) рупияләрне чит илләрдә алыштырырга рөхсәт бирми. Бары тик һинд товарларын гына сатып аласың, бетте-китте. Һинд базарында безгә кирәкле товарлар юк, сатып алганын да куярга урын юк әле. Банк хисабында рупия дигән зур саннар бар – бәясе кәнфит кәгазенә дә тормый. Аптырагач, индусларга нефтьне Дубай дирхәмнәренә һәм кайбер башка дус илләрнең валюталарына сатып алырга рөхсәт итеп карыйлар. Алары белән нинди проблемалар туасын белгән юк. Безнең өчен доллар да кәнфит кәгазе инде ул кәгазьлеккә. Вәләкин шул «фантик»ның бәясе үсә бит әле, шайтан аягын сындыргыры! Безнең байлар доллар фантигы белән ни эшләргә кирәген беләләр. Үткән ел Төркиянең күчемсез милек базарының 25 проценты россиялеләр кулында булган, 16 мең объект сатып алынган. Юк, җир тетрәгән төбәкләрдә түгел, имин урыннарда алынды күчемсез милек. Доллар менә шуңа булса да ярый. Рупия – барлык базарларда да файдасыз кәгазь.

Боларны уйласаң, исең китә. Нинди бай илдә яшәгәнбез һәм яшибез без. Акчаны үзебездә тотсак, илне гөлбакчага әйләндерә, технологик державага әверелдерә ала идек. Тик…

Рәшит ФӘТХРАХМАНОВ

Эльвира
ВӘЛИЕВА

КОЯШ КАЙДА АРЗАНРАК?

Әйдә, киттек Гаитига! Гаҗәпләнмәгез быел безне әнә шул тарафларга ял итәргә җибәрмәкчеләр. Ил Хөкүмәте әлегә сукмак та салынмаган илләр белән туризмны җайламакчы. Ә халык көтә. Сораштырудан күренгәнчә, илдә яшәүчеләрнең 70 проценты ял итәргә тели. Чит ил кояшы астындамы, әллә инде үзебезнеке дә ярыймы? Фикерләр төрле. Быел ялга өмет итәргәме-юкмы дигән сорауга «ВТ» хәбәрчесе җавап эзләде.

vk.com

2022 ел нәтиҗәләре буенча ил эчендә иң күп турист кунак иткән төбәкләр, млн кеше

Мәскәү өлкәсе	22 (+57%)
Мәскәү	18 (+7%)
Краснодар крае	17 (+3%)
Санкт-Петербург	8,1 (+32%)
Кырым	6,5 (–32%)
Казан	3,7 (+12%)
Төмән өлкәсе	3,3 (+13%)
Приморье крае	3 (+7%)
Ставрополье крае	1,5 (+20%)

Барбадос турындагы хыял

– Җәйгә өченче балабыз туачак. Шуңа күрә язгы каникулда гаиләбез белән чит илдә ял итеп кайтмакчы идек. Юлламалар белештек, бик кыйммәт. Мәсәлән, Мисырга дүрт кешегә көне буена җитәрлек ашау-эчү кергән бер атналык ял уртача 350 мең сумга төшә. Тик диңгезгә керә алмаячаксыз, салкын, дип кисәттеләр. Тайландта җылы, әмма бәяләре дә «тешле». Бер атналык ялны 500 мең сумга исәпләделәр. Шуңа күрә өйдә генә калырга булдык, – ди Чаллыда яшәүче Гөлназ Хәкимова.

Чит ил кояшы елдан-ел кыйммәтләнә. Моны белгечләр дә раслый. Башкаладагы туризм агентлыкларының берсендә эшләүче Диана Сафина сүзләренә караганда, быел җәй көне чит илгә юллама бәясе 50 процентка кадәр артырга мөмкин.

– Алдагы ел белән чагыштырганда, былтыр чит илгә юлламалар 30 процентка кыйммәтләнде. Сәбәпләре билгеле, әлбәттә. Узган ел күп кенә чит илләр Россия туристлары өчен ябылды. Европага очучылар 95 процентка кимегән әнә. Төркия, Мисыр кебек халык яратып йөри торган илләрдә уртача бәядәге отельләр ковид чорында ук ябылырга мәҗбүр булды. Махсус хәрби операция башлангач, һава юллары да чикләнде. Элек чит илгә 800ләп самолет очса, хәзер аларның саны 100гә дә тулмый. Туры рейслар саны аз. Өстәвенә чит ил очкычлары да безне урап узарга тырыша. Дөрес, Оманнан – Oman Air, Бәхрәйннән Gulf Air кебек яңа авиакомпанияләр ил базарына керә башлады, тик тармакта вазгыять тотрыклансын өчен вакыт кирәк. Туристлар үзләре дә чит илгә чыгып китәргә курка. Пандемиянең яңа дулкыны башлану, билгеле хәлләр аркасында ил чикләре ябылу, турфирманың банкротлыкка чыгуы кебек хәлләрдән беркем дә сакланмаган, – ди белгеч.

Россия Сак федераль хезмәтенең чик буе хезмәте мәгълүматларына караганда, былтыр безнең халык 23,2 миллион тапкыр ил чиген узган. Ял итәргә барыннан да бигрәк Төркиягә (3,7 миллион сәфәр), Берләшкән Гарәп Әмирлекләренә (909,7 мең), Мисырга (761,5 мең), Әрмәнстанга (295,7 мең), Тайландка (171,4 мең), Үзбәкстанга (131,6 мең), Казахстанга (113,3 мең), Мальдив утрауларына (94,5 мең), Азәрбайҗанга (92,7 мең) һәм Доминиканага (76,1 мең) барганнар.

Алга таба әлеге исемлек тагын да киңәймәгәе. Илнең Тышкы эшләр министрлыгы бу атнада гына 11 ил белән визасыз сәяхәт итү турында хөкүмәтара килешүләр төзергә җыенулары турында хәбәр итте. Бу – Бәхрәйн, Оман, Согуд Гарәбстаны, Багам утраулары, Барбадос, Гаити, Замбия, Күвәйт, Малайзия, Мексика һәм Триндад-Тобаго утрау-дәүләте. Күз күрмәгән, колак ишетмәгән утрауларга ил туристлары күпләп барып төшәчәге бик шикле, әлбәттә. Әлеге илләрнең кайберләренә икешәр очкыч белән тәүлектән артык барырга кирәк икәнен дә исәпкә алсаң, шул ук Барбадос хыялда гына калмагае.

Тик туристлар өйдә утырырга җыенмый. Узган айда безнекеләр рекорд та куйган хәтта. Февральдә Төркиянең Анталия шәһәренә 60 меңнән артык Россия туристы барган. Узган елның шушы ук чоры белән чагыштырганда, бу – ике тапкыр күбрәк.

– Әле яңа гына гаиләбез белән Анталиядәге Бәләк шәһәрендә бер атна ял итеп кайттык, – ди кечкенә кызы белән декрет ялында утыручы Сиринә Дорофеева. – Бик рәхәт булды, кояш җылы, һавасы шәп. Анда бар да тыныч. Гомумән, бирәдәге халык телевизор карамый, дөньядагы хәлләрне белми кебек тоелды. Сәүдә үзәкләре руслар белән тулган. Бездә ябылган кием-салым кибетләрендә һәр икенче сатып алучы рус телендә сөйләшә. Даруханәләрдә дә безнекеләр чират тора.

МАЙ БӘЙРӘМНӘРЕНДӘ ДҮРТ КЕШЕЛЕК ГАИЛӘГӘ БЕР АТНАГА ИҢ ОЧСЫЗ ЮЛЛАМАНЫ «ВТ» ХӘБӘРЧЕСЕ ДӘ ЭЗЛӘП КАРАДЫ

Ил, шәһәр	Ялның сыйфаты	Юллама бәясе (мең сум)
Мәскәү	Өч йолдызлы кунакханә, иртәнге һәм кичке аш	77,7
Санкт-Петербург	Өч йолдызлы кунакханә, иртәнге һәм кичке аш	76
Минеральные Воды, Ессентуки	Өч йолдызлы кунакханә, иртәнге һәм кичке аш	84,9
Сочи	Дүрт йолдызлы кунакханә, көне буена җитәрлек ашау-эчү	154,2
Төркия, Кәмәр	Дүрт йолдызлы кунакханә, көне буена җитәрлек ашау-эчү	173,8
Мисыр, Хургада	Дүрт йолдызлы кунакханә, көне буена җитәрлек ашау-эчү	233,7
Берләшкән Гарәп Әмирлекләре, Рас-әл-Хайм	Биш йолдызлы кунакханә, иртәнге һәм кичке аш	233,8
Тайланд	-----	-----

Tourvisor.ru сайтыннан

Тынычлык кадерлерәк

Үгез булмагае, чурт булсын, дигәндәй, чит ил кояшы ерагайган арада эчке туризмны үстермәкчеләр. Быел Россия буйлап сәяхәт итүгә өстенлек бирүчеләр 10 процентка артачак, дип фаразлаган Россия туризм индустриясе берлеге президенты Илья Уманский.

– Иртәгә ниләр буласы бүген билгесез. Шуңа күрә ял турында хыялланучылар ил буенча юллама сорап мөрәҗәгать итә. Узган елның шушы ук чоры белән чагыштырганда, гыйнвар – февраль айларында Россия буенча сәяхәт итәргә теләүчеләр саны 35 процентка артты. Былтыр күбрәк Кырым курортлары белән кызыксындылар, быел илнең төрле шәһәрләренә өстенлек бирәләр, – ди Әлмәттә юллама лар сату белән шөгыльләнүче Гөлнара Вилданова.

Дөрес, Кырымга ял итәргә баручылар 30 процентка кадәр кимеячәк, дип фаразлаучылар да бар. Чүп өстенә – чүмәлә: белгечләр, быел Кырымда Төркиядәге кебек көчле җир тетрәүләр булырга мөмкин, дип тә куркытты. Былтыр ял өчен ярымутрауны сайлаучыларга да җиде кат уйларга туры килгән әнә.

– Узган җәйдә гаилә дусларыбыз белән өч машинада ун көн Кырымда ял итеп кайттык. Куркытты, әлбәттә. Тик диңгез буенда ял итү теләге көчлерәк иде. Юлга кузгалганчы ярымутрауда булып кайткан таныш-белешләрдән барысын да тәгаен сораштык. Тамань аша Азов диңгезе яры буйлап Межводное авылына кадәр бардык. Анда астан гына очып киткән вертолетлар, очкычларны күп күрдек, истребительнең колакны ярып кердерәй тавышының ни икәнен дә яхшы беләм хәзер. Ялның күп өлешен Севастопольдә үткәрдек. Анда тыныч иде, туристлар да күп. Кырым бик матур, әмма быел анда ял итәргә бармыйбыз. Тынычлыгың мең өлеш артык, – ди былтыр Кырымда ял иткән Алинә Мостафина.

Гөлнара Вилданова әйтүенчә, бу кышта Байкал күленә юллама сатып алучылар саны арткан. Бәяләргә килгәндә, мәсәлән, апрель башында күл буенда бер кешегә биш көнлек ял 20 мең сумнан башлана. Бу бәягә Казаннан очкычта ике якка билет һәм иртәнге аш кергән.

Башкалада яшәүче Лилия һәм Фәрит Насыйровлар бер-берсенә 23 февраль һәм 8 Мартка Байкалга бүләк ясаганнар.

– Казаннан төнге сәгать уникедә тулганда очтык, Иркутскига иртән барып җиттек, – дип сөйләде Лилия Насыйрова. – Бер якка биш сәгать тирәсе очасы. Туристлар яратып йөри торган Листвянка, Голоустное бистәләрендә, Ольхон утравында булдык. Алар барысы да Иркутскидан якынча 200–300 чакрым ераклыкта урнашкан, Листвянка гына бераз якынрак. Юл шактый вакытны ала, кыскасы. Экскурсияләргә гид белән йөрисе. Үзең машина яллап, бозга керсәң дә була. Сәяхәтебезнең төп максаты Байкалны күрү булгач, күбрәк бозда булырга тырыштык. Шактый ук салкын булса да, бозда йөгереп тә, утырып та, ятып та карадык. Фотосурәтләрдәге матур бозны күрү өчен квадроциклларда әчкә керергә кирәк. Кайтып китәр алдыннан Иркутскиның үзен дә күреп чыктык. Шәһәр әллә ни гаҗәпләндермәде. Безнең Алабугага охшаган. Туристлар алай күп дип әйтмәс идем. Хәзер Байкал күлендә сезон бетеп бара. Бәлки, бу шуңа да бәйледер.

Казанга хатын-кызлар килә

Туризм агентлыкларының берсе үткәргән сораштырудан күренгәнчә, илдә яшәүчеләрнең 70 проценты: «Ял кирәк!» – дигән фикердә. Быел респондентларның 30 проценты диярлек ял чорында чит илгә барырга хыяллана. Ил буенча сәяхәт итәргә җыенучыларның яртысы – билгеле хәлләр аркасында, чит илдә ял итү турындагы карарны кичектереп торучылар.

«OneTwoTrip» ялны оештыру онлайн хезмәте бу җәйдә туристлар арасында популяр булачак ил шәһәрләре исемлеген дә төзегән. Беренче урында – Мәскәү. Коямлы Сочи – икенче. Санкт-Петербург – өченче урында. Беренче бишлеккә Казан һәм Калининград та эләккән.

Былтыр Татарстанда 3,7 миллион турист кунак булган. Алдагы ел белән чагыштырганда, бу 12 процентка күбрәк. Татарстан – ел дәвамында иң күп турист кабул иткән ил төбәкләре арасында бишенче урында. Без Мәскәү, Санкт-Петербург, Кырым һәм Краснодар краена гына уздырган. Республиканың Туризм буенча дәүләт комитетында Татарстанга кемнәр килгәнен дә ачыклаганнар.

– Безгә күбрәк хатын-кызлар килә. Былтыр республикада 1,8 миллион гүзәл зат һәм 1,7 миллион ир-ат кунак булган. Туристларның күбесе 25–34 яшьтә. Татарстанга килүче туристларның уртача кереме 30–50 мең сум тәшкил итә. Аена 100 мең сумнан да күбрәк акча алып эшләүчеләр республикага сирәк килә, – дип сөйләде комитет җитәкчесе Сергей Иванов ел йомгакларына багышланган утырышта.

Туристларны җәлеп итү өчен республикада кэмпинг һәм глэмпингны да үстермәкчеләр. Табигать кочагында 230лап шундый экологик йорт барлыкка киләчәк, дип фаразлана. Мәсәлән, Яшел Үзән районында урнашкан шундый бер «түбә»не ялларда бер тәүлеккә арендага алып тору, ашау-эчүдән башка, ике кешегә 18 мең сумнан башлана. Өйдән читтә ял итәм дисәң, барыбер түләргә туры киләчәк.

Кыю туташлар

Ләйсән – күрше кызы. Моннан ике ел элек тугызынчы сыйныфны тәмамлагач, Әтнәдәге авыл хуҗалыгы техникумына укырга керде. Ветеринария табибы булырга укый. Аның бу һөнәрне сайлавына аптырадык та, аптырамадык та. Бала чактан мал-туар арасында мәш килеп үскәнен, ул чакта авыл фермасында эшләүче әнисе янына көн саен диярлек төшүен, дуңгызлардан курыкмавын да беләбез ләбаса. Ә икенче яктан, замана кызларына бит чистарак, төшемлерәк эшләр дә шактый…

Без авыл гадәте белән генә шулай дип уйлыйбыз. Баксаң, ветеринар һөнәре хәзер кыз балалар арасында шактый популяр икән. Социаль челтәрдәге мәгълүматларга ышансаң, бигрәк тә тугызынчы сыйныфны тәмамлаучы кызлар бу һөнәргә күбрәк тартыла, ветеринар белгечлеге алар сайлаган иң актуаль дүрт һөнәр арасына керә, ә авыл хуҗалыгы белгечлеге буенча – беренче урында.

– Беренче курста укыганда этләр-песиләр дәвалармын дип уйлаган идем, – ди күршебез Ләйсән дә. – Әмма безгә практика буларак, мәчеләргә укол-прививкалар кадау, стерильләштерү процессларын күрсәттеләр. Кечкенәдән песиләрне бик яраткангадыр, мин аларны бик җәлләдем. Өстәвенә алар бик сабырсыз, аларга укол кадау да шактый куркыныч, сыер малы күпкә сабыр дип, шушы юнәлешне сайларга, укып бетергәч, авылга кайтырга булдым.

– Сезнең төркемдә тагын кызлар бармы соң? – дип сорыйм Ләйсәннән.

– Егетләр әзрәк тә әле, – ди ул. – Арада шәһәр кызлары да бар, Мари Иленнән килүчеләр дә, якын-тирә районнардан да бар. Балтачтан өч кыз бергә укыйбыз.

– Шәһәр кызлары ветклиникаларда эшләргә җыенадыр инде, – дим, аларның сыер-бозаулардан куркасына тамчы да шикләнмичә.

– Юк, – дип көлә Ләйсән. – Алар сыерлар янында да китми. Быел без – өченче курста, теориягә караганда практика күбрәк. Фермадан кайтып та кермибез.

– Үткән җәй Ләйсән минем белән фермада бозаулату бүлегендә эшләде, – дип әңгәмәгә кушыла әнисе Фәйрүзә. – Авырып киткән кулдашым урынына кара-каршы эшләдек. Шөкер, ферма мөдире дә, баш зоотехник та бик яратып калды үзен. «Безгә кайт», – дип чакырдылар.

– Мин әни белән сыерлар карап кына калмадым, бөтен ветеринария эшләренә дә катнаштым, – ди Ләйсән. – Быел техникумга баргач, укытучылар да: «Син боларны каян беләсең?» – дип сорады әле… Мастит төрләре турында без бу уку елында гына өйрәндек, миңа инде фермада күпне аңлатканнар иде…

– Быел кыш этебез ашамас булды, бик ябыкты, үләр инде дигән идек. Ветеринарларга әйтмәдек, Ләйсән үзе укол-дарулар алып кайтып, тәки аякка бастырды, – дип сөенә әнисе. – Берничә ел элек бозавыбызны сырып алган урман бетләрен дә, курыкмыйча, аның белән икәү чистарткан идек… Бала чакта көтүгә чыгарга атлыгып торды. Авылдагы бөтен кешенең сыерын таный иде… Әле бит кем сыеры икәнен тану өчен, авылның теге очындагы кешеләрне дә белергә кирәк дип аптырый идем үзем дә…

Бүген һәр йортта табиб, юрист һәм компьютерчы булса, шәп, диючеләр бар. Без, авылда яшәүчеләр, бу исемлеккә мал табибын да өстибез. Өендә үк булмаса да, күршеңдә булса да, начар түгел, билгеле. Авылга кайтам дигән һәр кешегә, һәр сүзгә дә сөенәбез бит әле…

Гөлсинә ХӘБИБУЛЛИНА

МАЛ – ФАЙДАГА

Сөт җитештерү һәм ашлык үстерү буенча рекорд куелган, аның каравы ит җитештерү кимегән, эре агрохолдингларда терлекләр бетерелә, комплекслар төзелеп, вак фермаларның ишекләренә кадак кагыла, ашлык һәм сөт бәяләре дә борчу тудыра. Татарстан Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгының еллык утырышында литр һәм центнерларның сала кешесенә ничек йогынты ясаганы турында сөйләштеләр.

Илдар Мөхәммәтҗанов

Уңышлар

Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министры Марат Җәббаров сүзләренә караганда, узган ел республикада 5,2 млн тонна ашлык җыеп алынган, республика тарихында беренче тапкыр 2 млн тоннадан артык сөт савылган. Ил төбәкләре арасында Татарстан сөт җитештерү буенча – беренче, бәрәңге үстерү буенча – икенче урында. Терлек һәм кош ите, ашлык, йомырка һәм шикәр чөгендере җитештерү буенча республика ил төбәкләре арасында беренче унлыкка керә. Республикада ит, сөт, ашлык белән тәэмин ителеш 100 процентны тәшкил итә, шикәр һәм бәрәңге буенча 200 проценттан артып китә. Татарстан авыл хуҗалыгы продукциясе җитештерү буенча төбәкләр арасында беренче бишлеккә кайтты.

Хезмәт хакы

Узган ел авыл хуҗалыгы оешмалары буенча акчалата керем – 20 процентка, хуҗалыкларның табышы 6 процентка арткан. Тармакка керткән өлешләре буенча лидер районнар – Тукай, Кукмара, Әтнә, Балтач һәм Саба. Шулай ук Мөслим һәм Тәтеш районнары да яхшы күрсәткечләргә ирешкән. Алар беренче унлыкка күтәрелгән. Кайбыч, Кама Тамагы, Яңа Чишмә һәм Бөгелмә районнары да уңышлары белән сөендергән. Ә менә Яшел Үзән һәм Питрәч районнары беренче унлыктан төшеп калган.

Рейтингны билгеләгәндә бер гектар сөрүлек җиреннән алына торган керем зур роль уйный. Кемдер гектардан – нибары 16 мең, кемдер – 100 мең сум, комплекслары булган районнар 300 мең сумга кадәр керем кертә. Министр үрнәк итеп Саба, Кукмара һәм Әтнә районнарын китерде. Шул ук вакытта Әгерҗе, Югары Ослан, Баулы, Спас һәм Балык Бистәсе районнарының сатылган продукция күләме республикадагы җир өлешеннән күпкә кимрәк.

Соңгы 4 елда авыл хуҗалыгы тармагында хезмәт хаклары арткан. Марат Җәббаров сүзләренчә, ул 62 процентка күтәрелеп, айга уртача 39 мең сумга җиткән. Дөрес, төрле җирдә төрлечә. 60 мең сум түләгән хуҗалыклар да, көч-хәл белән 20 мең сум җыеп бирүчеләр дә бар. Министр китергән мәгълүматлар буенча, хезмәт хаклары комплекслар булган районнарда (Яшел Үзән һәм Тукай районнары) зур. Шулай ук Әлмәт, Бөгелмә, Мамадыш районнарында да авыл хуҗалыгы хезмәткәрләре яхшы акча алып эшли. Эре инвесторлар булмаса да, Тәтеш, Кукмара, Әтнә һәм Балтач районнары позицияләрен бирми. Ә менә Әгерҗе, Балык Бистәсе, Апас, Спас һәм Баулы районнарында акча мәсьәләсендә хәлләр мактанырлык түгел.

Игенчелек

«Безгә ашлыкның рекордлы уңышы аның бәясен төшерүен дә исәпкә алырга кирәк, – дип сөйләде министр. – Бүген аның бер тоннасы 8 меңнән 11 мең сумга кадәр. Бу – узган ел белән чагыштырганда ике тапкырга азрак».

Дөрес, аграрийларга сатылган ашлыкка субсидияләр булачагын хәбәр иттеләр. Рөстәм Миңнеханов чит илдән кертелә торган техник культура орлыкларына бәйлелек зур булуын әйтте. Ул бу проблеманы федераль дәрәҗәдә хәл итәргә, аларны җитештерә торган үзәкләр булдырырга тәкъдим итте.

ТАТАРСТАНДА ҖИТЕШТЕРЕЛӘ ТОРГАН ТӨП АВЫЛ ХУҖАЛЫГЫ ПРОДУКЦИЯСЕ


Ашлык – 5210,7 мең тонна (↗+ 20 процент).

Шикәр чөгендере – 1931,2 мең тонна (↗+ 44 процент).

Сөт – 2003,5 мең тонна (↗+ 3,8 процент).

Терлек һәм кош ите – 527,1 мең тонна (↘– 2,1 процент).

Йомырка – 1537,9 млн данә (↗+ 1,7 процент).

Терлекчелек

Республикада иң күп сөт Кукмара, Саба, Минзәлә, Әтнә, Балтач һәм Бөгелмә районнарында савыла. Әйтик, Кукмара районы сыерлары тәүлегенә – 400, Сабанныкылар 300 тонна сөт бирә. Шулай ук беренче унлыкка Мөслим, Мамадыш, Азнакай һәм Алабуга районнары керә.

Шул ук вакытта узган ел сөт күләмен киметкән районнар да бар. Болар – Әлки, Яшел Үзән, Чистай, Лаеш һәм Югары Ослан районнары.

Марат Җәббаров фикеренчә, яхшы күрсәткечләргә яңа инвестпроектларны тормышка ашыру нәтиҗәсендә ирешелгән. Узган ел 18 мең сыерга исәпләнгән 24 сөт комплексы төзелгән. Тагын 15,5 мең сыерга исәпләнгән 22 проект тормышка ашырылачак. Бу елына 60 мең тонна өстәмә сөт дигәнне аңлата.

– Быелның февраленнән сөт сатып алу бәяләре төште. Сезонлы күренеш булса да, башка елларга караганда иртәрәк булды. Проблеманы хәл итү өчен сөтне эшкәртүче дә, җитештерүче дә канәгать калырдай тотрыклы бәя белән озак вакытлы килешүләр төзергә кирәк, дип саныйбыз, – диде Марат Җәббаров.

Министр эре авыл хуҗалыгы оешмаларында терлек саны кимүенә дә борчылу белдерде. Узган ел 16 мең терлеккә азайган.

Нигездә эре инвесторлар – «Красный Восток Агро», «Ак Барс Холдинг», «Агросила» һәм «Август-Агро» киметә. Әйтик, «Красный Восток» агрофирмасы 8 мең терлеген юкка чыгарган, сөт җитештерү күләме 18 процентка кимегән.

«Апас Мол» (Апас) һәм «Заря» (Буа районы) агрофирмаларында сыерларның бәрәкәте 22 процентка кимегән. Лидер хуҗалыклар ел саен бер сыерга 10–13 мең кг сөт савып алганда, бу агрофирмаларда әлеге күрсәткеч нибары 3,3–2,9 мең килограммны тәшкил итә. Дөрес, кайбер компанияләрдә сыерларны сәламәтләндерү, яңарту процессы бара.

Ферма бетсә, авыл бетә

Татарстан Рәисе Рөстәм Миңнеханов та тармактагы авырткан мәсьәләләргә тукталды. Ашлык күп икән, аны терлекчелектә файдаланырга кирәк.

– Безнең республика терлекчелек белән шөгыльләнә. Логистика белән проблемаларны искә алып, безгә ашлыгыбызны үз терлекчелегебез аша уздырырга кирәк, – диде ул.

Ләкин Чүпрәле һәм Кама Тамагы районнары, мәсәлән, ел буена бер баш токымлы терлек тә сатып алмаган. Рөстәм Миңнеханов бер генә инвестиция проектын да тормышка ашырылмаган тугыз районга (Чүпрәле, Яшел Үзән, Сарман, Югары Ослан, Балык Бистәсе, Менделеевск, Әлмәт, Лаеш һәм Питрәч) шелтә белдерде.

– Бу бит сөт кенә түгел, бу – анда эшләүче кешеләрнең һәм хуҗалыкларның керемнәре, – диде Татарстан Рәисе.

Ул шулай ук инвесторларның терлек санын киметүенә дә игътибар итте.

– Бу – зур проблема, – диде Рөстәм Миңнеханов. – Моны вакытлыча гына күренеш дип уйлыйк. Инвестор килә, аңлашыла инде, матди база юк. Чистайда инвесторның терлек санын бетерүе аркасында биш авыл халкы эшсез калды. Зәй, Яшел Үзән, Яңа Чишмә һәм Югары Ослан районнарында шундый ук хәл. Әгәр болар вакытлыча булса, аңларга була. Ләкин без бернинди дә карарлар кабул итмәсәк, бу авыллар акрынлап юкка чыгачак. Эшсез булмый. Терлекчелек авыл халкы тормышында бик мөһим.

Терлекчелектә алдыра алмаган районнарда хезмәт хакы да түбән. Ахыр чиктә бу халык санына да йогынты ясый. Монысын да Татарстан Рәисе әйтте. Хезмәт хакы түбән булгач, яшьләр дә килми. Авыл хуҗалыгында эшләүчеләр арасында яшьләрнең саны 10 проценттан да кимрәк. Узган ел укуын тәмамлаган яшьләрдән авылда нибары 61 кеше калган. Ә республикада елына 2 меңгә якын белгеч әзерләнә. Аларны ничек тә авылга кайтару ягын карарга кирәк – Татарстан Рәисе министрлыкка куйган бурычларның берсе әнә шул булды.

Зөһрә САДЫЙКОВА

БЕЗГӘ ДИГӘН КЫЗ ТУМАГАН!

Илдар Мөхәммәтҗанов

< Ахыры. Башы 1 нче биттә

Гаилә коручы Татарстан хатын-кызларының уртача яше – 25 яшь. Ә Россия күләмендә – 26 яшь.

Кәләшләр кытлыгы

Татарстан авылларында – кәләшләр кытлыгы. Моның сәбәбе – яшьләр миграциясе. Бу хакта Дәүләт Советының Бюджет буенча комитеты утырышында Хисап палатасы аудиторы Сергей Колодников белдерде.

Сергей Колодников китергән саннарга ышансаң, 25–34 яшьлек ир-атлар күп, бу яшь аралыгында булган гүзәл затлар бермә-бер азрак икән. Бу инде гаилә коручылар санына да тәэсир итә, билгеле. Авылда калыргамы-юкмы дип баш ватканда да, җавапны тизләтер өчен бер сәбәп ул.

Бер уйласаң, күпме нәрсә хатын-кызга бәйле булып чыга бит. Авыллар яшәсен өчен, гаилә коручылары, салада бәби табучылары кирәк. Бәби табар өчен гүзәл затлар кирәк. Ә алар, сөер яңгыраса да, күп тә, тик юк та.

Татарстан Фәннәр академиясенең Гаилә һәм демография үзәге директоры Чулпан Илдарханова әйтүенчә, 2007 елдан башлап 2016 елга кадәр хатын-кызлар саны кимүгә таба барган. Әмма бәби алып кайтучылар саны, киресенчә, арткан. Билгеле, моңа сәбәпче – ана капиталы. Белгеч аңлатканча, хәзер инде ана капиталы турында хыялланган гүзәл затлар үзләренең репродуктив мөмкинлекләрен тормышка ашырган. Шуңа күрә дәүләткә дә хәзер яңа ярдәм чаралары турында уйларга кирәк.

Хәзерге заманда мөнәсәбәтләр турында уйлаганда, танышам дигәндә, мөмкинлекләр күп инде ул. Хат язып, айлар буе җавап көтеп тилмерәсе, «разведка»га кемнедер җибәрәсе юк бит. Теләк дигәне генә җитми әллә? Бу җәһәттән яшәргә өйрәтүче коуч, психологларның мөстәкыйльлек культын алга сөрүләре, «үзеңне генә ярат» дигән шигарьләре дә тәэсир итми калмыйдыр, билгеле.

Гаилә кору турында сөйләгәнче, яшьләрне таныштырырга да кирәк бит әле. Россия Мөселман хатын-кызлар берлеге рәисе, Гаилә кору һәм саклау үзәге директоры, яучы Наилә Җиһаншина 3 меңгә якын парны таныштырган. Аның сүзләренчә, никахка кадәр үк шәхеснең яхшы һәм яман якларын күрергә өйрәтергә кирәк.

– 2010 елда таныштыра торган үзәк булдырдык. Һәр районда яучыларыбыз бар. Кияүгә чыкмаган хатын-кызлар, өйләнмәгән ир-егетләр турында хәбәрләр алып торабыз. Үзәк ярдәме белән 3 меңләп кеше парын тапты. Кешенең бит кимчелекләрен дә алдан күрергә кирәк. Никахтан соң күзләр ачыла, диләр. Безнең максат – күз, колак, җанны ачу. Аерылышучылар да бардыр, әмма кавыштырган парларның 80 проценты гаилә булып яши, – диде Наилә Җиһаншина.

Шәм яндырып эзләсәң дә…

Кызлар гына түгел, егетләр дә кала ягына карый. Шагыйрә, Әтнә кызы Гөлүсә Батталова әйтүенчә, авыл җирендә үскән яшьләр дә киләчәген авыл хуҗалыгы белән бәйләми.

– Яшьләрнең китүе эш урыннары җитмәүгә бәйле. Кемдер табиб, инженер булырга тели, таможняда эшләргә дип укый. Авыллар, район үзәкләре мондый профессия үзләштергән яшьләрне эш белән тәэмин итә алмый бит, – дигән фикердә ул. – Авыл җирендә, нигездә, авылны бик яраткан һәм киләчәген дә шушында күргән кешеләр генә кала. Безнең Әтнәдә дә төп эшчәнлек – авыл хуҗалыгы. Аннан соң гына башка төр һөнәрләр китә. Тик мин яшьләр аз димәс идем. Төпләнеп калганнары күп.

Әңгәмәдәшебез дә – авыл егетен яр иткән кеше. Район үзәгендә дә түгел, авылда яши алар. Гөлүсә Батталовадан сала егетенә кияүгә чыгып, авыл тормышы белән яшәүнең уңай якларын барлавын сорадык.

– Ел әйләнәсе саф һавалы авыл җирендә торам. Капка төбенә чыгып бассам да, табигать, матурлык. Мәсәлән, Казанда кышның бөтен матурлыгын тоеп, күреп яшәп булмыйдыр ул. Чын табигать – авылда, – ди ул. – Минем өчен төп факторларның берсе – тынычлык. Казан шау-шуы минем өчен түгел. Авыл җирендә «бөке»дә дә утырмыйсың. Район үзәгенә мин биш минутта барып җитәм. Район үзәгендә сәнгать, спорт мәктәбе, бассейн, театр эшли, аларга да юлым «бөке»сез, тоткарлыксыз. Казанда ыгы-зыгыга туры килсәң, күпме вакытың уза, машина кую урыны эзләп интегәсең. Анннан татар телен саклау мәсьәләсенә дә кагылырга кирәктер. Авыл җирендә укыган баланың теле сафрак дип әйтер идем. Мин авылны бик яратам. Башкалабызга сагынып, кунак булып килергә яратам.

Яңа Чишмә районындагы Чертуш авылыннан Рәмзия Мусина да егет-кызлар җитмәвен эш урыннары юклыктан күрә.

– Безнең авыл олы юлдан ераграк. Без юл буенда гына торсак, бәлки, авыл кызлары монда калып, үзәккә йөреп эшләү җаен табар иде. Буйдак егетләр бар. Безнең авылда да бар алар. Авылны яшәртәсе килә, билгеле. Күреп торасыз, алар бетә бара. Күпме язучылар, күпме шагыйрьләр, хәтта Татарстан Рәисе үзе дә – авылдан чыккан кеше. Авыллар бетсә, нәрсә булыр икән дип уйлап, борчылып та куям, – ди Рәмзия ханым. – Җитәкчеләр игътибарыннан башка проблемадан чыгу юлын табып булмыйдыр ул. Әйтик, үз эшен башлаган яшьләргә ярдәм итү, аларга зур салымнар түләтмәү… Алар авылда үзен тапса, эшләсә, төпләнеп калыр иде бит. Үзебезнең авылда да бар андый тырышлар. Фермалар тоталар, өчәр-дүртәр бала үстерәләр. Мин аларга сокланам. Авылда калуның тагын бер сәбәбе – эшне ярату, димәк. Хәзер су, газ кергән, авылда тырышып эшлисе генә бит.

Әңгәмәдәшебез үзенең яшьлеген дә мисал итеп китерде.

– 1990 нчы елларда безнең колхоз аерылып чыкты да һәркемгә эш тә булды. Колхоздан һәр кешегә йорт бирделәр. Яшьләр шул мөмкинлектән файдалана алды, гаилә корды, төпләнеп калды, балалар тапты. Ул вакытта миңа шундыйрак ярдәм булган бит. Яшәеш нигезен авылда күрәм. Авылдагы буш йортларны күреп, йөрәк әрни, – диде ул.

Чулпан ГАРИФУЛЛИНА

Белгеч сүзе

Ольга МЕЖЕНИНА, гаилә психологы:
– Еш кына яшьләрнең гаилә кормавы социаль калыпларга бәйле түгел. Бу адымга әзер булмау – төп сәбәп. Ир-атларга килгәндә, аларның репродуктив яше, хатын-кызларныкы белән чагыштырганда, зуррак булуын исәпкә алырга кирәк. Ялгызлыгын аеруча сизгән очракта, кеше барыбер гаилә корырга омтылачак. Әгәр дә кеше парлы яшәү тормышта нәрсәгә дә булса киртә куяр дип уйлый икән, нишләп алай уйлаганын ачыкларга кирәк. Кеше – социаль зат. Иртәме-соңмы, кемнедер яратасы, кем турындадыр кайгыртасы килү теләге уяначак. Бу – тормыш-яшәешнең төп шарты. Кеше җаваплылык өчен өлгерергә тиеш.

«ВКонтакте»дагы төркемебездәге сораштыруга килгән фикерләр

Марат: «Яшим, эшлим дигән кешегә шәһәрдәгеләрдән дә яхшырак яшәп, эшләп ятучылар күп авылларда. Егетләрнең үз бизнесы бар, көттә машиналарда йөриләр, ләкин өйләнмәгән. Авылга кайтып торырдай кызлар юк».
Анфиса: «Әнисе белән бер өйдә яшәсә, өйләнми инде ул. Чөнки карап торучысы бар».
Сәгабҗәп: «Авылда туып-үскән булсам да, кызымның авылга кайтып торуына каршы мин. Бай егет булса да. Күпләр шулай ди».
Эльмира: «Бүген өйләнергә әзер егетләр бар. Кызлар теләми авылга кайтырга. Авылда шундый танышлар күп».
Илдус: «Экскурсияне эмиграция белән бутамагыз. Бер киткән кеше кире кайтмый авылга».
Илшат: «Минем хатыным авылны ярата, мин – шәһәрне. Әлегә шәһәрдә торабыз».

РОССИЯДӘ ЯШИ: 146424729 КЕШЕ.
36789914е АВЫЛЛАРДА ГОМЕР ИТӘ.
Хатын-кызлар: 15 процентка күбрәк (2001 елдан бирле).
Авыл җирлегендә **1000** ир-атка **1070** хатын-кыз туры килә.
Татарстан авылларында – **474944**, шәһәрләрдә **1660029** хатын-кыз яши.
Казанда – **716,3** мең хатын-кыз. Авылда яшәүче хатын-кызның уртача яше – **45** яшь.
Республика буенча – **42**.

**Росстат һәм Татарстанстат мәгълүматларына нигезләнеп*

13 март | Дүшәмбе

ВГТРК ТАТАРСТАН
05.05, 06.05, 07.05, 08.05 «Вести-Татарстан. Погода»
05.35, 06.35, 07.35, 08.35 «Вести-Татарстан. Утро»
09.00 «Яңалыклар. Татарстан»
09.30 «Хәерле көн, Татарстан!»
14.30, 21.05 «Вести-Татарстан»

ТНВ ТАТАРСТАН – ЯҢА ГАСЫР
06.00, 07.10 «Манзара». Мәгълүмати-күңел ачу программасы 16+
07.00, 18.30, 20.30, 05.50 Татарстан хәбәрләре 16+
08.00, 14.30, 19.30, 21.30 Новости Татарстана 16+
08.10 «Здравствуйте!» 16+
09.00, 17.00 «КӨТЕЛМӘГӘН КУНАК». Телесериал 16+
10.00, 23.00 «ИДЕАЛЬНАЯ ЖЕНА» 16+
11.00 «Канун. Парламент. Җәмгыять» 16+
11.30, 16.30 «Заман көзгесе» 6+
12.00, 22.10 «БӘХЕТ КЫЙПЫЛЧЫКЛАРЫ» 12+
13.00 «Семь дней». Информационно-аналитическая программа 16+
14.00 «Закон. Парламент. Общество» 16+
14.45 «Моң чишмәсе» 16+
15.15 «Шаян ТВ» тәкъдим итә» 0+
16.00 «Переведи!» (учим татарский язык) 6+
18.00 «Әдәби хәзинә» 16+
19.00 «Таяну ноктасы» 16+
20.00, 22.00 «Вызов 112» 16+
20.15 «Күчтәнәч» 0+
21.00 «Tatarstan today. Открытый миру» 16+
00.00 «Здоровая семья: мама, папа и я» 12+
00.15 «Если хочешь быть здоровым» 16+
00.30 «Таяну ноктасы» 16+
01.00 «Ком сәгате» 16+
02.00 «Манзара». Мәгълүмати-күңел ачу программасы 16+
03.30 «Әдәби хәзинә» (субтитрлы) 16+
03.55 «Йөрәктән – йөрәккә» (субтитрлы) 16+
04.45 «Җырлыйк әле!» 12+
05.35 «Оныта алмыйм...» 12+

ТНВ-ПЛАНЕТА
06.00, 13.05, 01.05 «Манзара». Мәгълүмати- күңел ачу программасы 16+
08.00, 00.40 «Үткәннәр сагындыра» 12+
08.40, 23.05, 04.15 «Башваткыч» 12+
09.50 «Семь дней». Информационно-аналитическая программа 16+
11.00, 15.00, 18.00, 21.00, 00.00 «Яңалыклар» 16+
11.30 «Туган җир» 12+
12.05, 18.20, 21.25 «ЯЗМЫШЛАРДАН УЗМЫШ ЮК ИКӘН» 16+
15.30, 20.30 «Заман көзгесе» 6+
16.00 «Әдәби хәзинә» (субтитрлы) 6+
16.30 «Шаян ТВ» тәкъдим итә... 6+
17.00 «Моң чишмәсе» 16+
17.30 «Ватандашлар» 16+
19.20, 22.20, 03.25 «Тибрәнә җыр дулкыннары» 12+
19.30 «Калеб» 6+
20.00 «Таяну ноктасы» 16+
00.15 «Канун. Парламент. Җәмгыять» 16+
02.50 «Караоке татарча» 12+
03.00 «Әдәби хәзинә» (субтитрлы) 6+
05.05 «Әй, язмыш, язмыш...» (субтитрлы) 16+

1 КАНАЛ
05.00 Телеканал «Доброе утро»
09.00 Новости (с субтитрами)
09.20 Премьера. «АнтиФейк» 16+
09.55 «Жить здорово!» 16+
10.45 Информационный канал 16+
12.00 Новости (с субтитрами)
12.15 Информационный канал 16+
15.00 Новости (с субтитрами)
15.15 Информационный канал 16+
16.00 «Мужское/Женское» 16+
16.50 Информационный канал 16+
18.00 Вечерние новости (с субтитрами)
18.20 Информационный канал 16+
21.00 «Время»
21.45 Премьера. Мариэтта Цигаль-Полищук. «РАНЕВСКАЯ» (S) 12+
22.40 «Большая игра» 16+
23.40 ПОДКАСТ.ЛАБ «Фаина Раневская» 16+
00.20 ПОДКАСТ.ЛАБ «Триггеры» 16+
01.00 ПОДКАСТ.ЛАБ «Собрались с мыслями» 16+
01.40 ПОДКАСТ.ЛАБ «Письма» 16+
02.20 ПОДКАСТ.ЛАБ «Кот Шрёдингера» 16+
03.00 Новости
03.05 ПОДКАСТ.ЛАБ «Космические истории» 16+
03.40 ПОДКАСТ.ЛАБ «АстроУмные» 16+
04.15 ПОДКАСТ.ЛАБ «Психика» 16+

РОССИЯ 1
05.00 «Утро России»
09.00 Местное время. Вести-Татарстан
09.30 «Утро России»
09.55 «О самом главном». Ток-шоу 12+
11.00, 1400, 16.00, 20.00 Вести
11.30 «60 минут». Ток-шоу 12+
14.30 Местное время. Вести-Татарстан
14.55 «Кто против?» Ток-шоу 12+
16.30 Премьера. «Малахов» 16+
17.30 «60 минут». Ток-шоу 12+
21.05 Местное время. Вести-Татарстан
21.20 Русская серия. Премьера. Ирина Пегова, Ярослав Бойко, Наталья Гудкова, Александр Макогон, Максим Радугин и Владислав Резник. «АКУШЕРКА. НОВЫЕ СЕРИИ» 16+
23.25 «Вечер с Владимиром Соловьёвым» 12+
02.05 «ДУЭТ ПО ПРАВУ» 12+
03.55 Анна Гарнова, Илья Шакунов, Никита Панфилов, Борис Невзоров, Екатерина Кистень. «ЛИЧНОЕ ДЕЛО» 12+

МАТЧ ТВ
06.00, 13.45 «Спортивный век» 12+
06.30 Футбол. Журнал Лиги чемпионов 0+
07.00, 10.00, 12.20, 14.15, 16.20, 19.50 Новости
07.05, 19.00, 21.55, 00.30 Все на Матч! Прямой эфир
10.05, 12.00 Специальный репортаж 12+
10.25 Смешанные единоборства. UFC. Рафаэль Дос Аньос против Рафаэля Физиева. Трансляция из США 16+
11.30 «Здоровый образ. Фигурное катание» 12+
12.25 «Есть тема!» Прямой эфир
14.20 Футбол. МИР Российская Премьер-Лига. Обзор тура 0+
15.20 «Громко» Прямой эфир
16.25 «Что по спорту? Вологда» 12+
16.55 Футбол. МЕЛБЕТ-Первая Лига. «Алания-Владикавказ» – «Кубань» (Краснодар). Прямая трансляция
19.55 Баскетбол. Единая лига ВТБ. «Зенит» (Санкт-Петербург) – ЦСКА. Прямая трансляция
22.30 Профессиональный бокс. Джеф Монсон против Артура Варданяна. Басир Абакаров против Виталия Кудухова. Прямая трансляция из Москвы
01.25 Матч! Парад 16+
01.55 Футбол. Чемпионат Германии. «Вольфсбург» – «Унион» 0+
03.55 Новости 0+
04.00 «Наши иностранцы» 12+
04.30 Гандбол. Чемпионат России. OLIMPBET Суперлига. Женщины. «Ростов-Дон» (Ростов-на-Дону) – «Динамо-Синара» (Волгоград) 0+

НТВ
04.55 Сериал «МОСКВА. ТРИ ВОКЗАЛА» (S) 16+
06.30 «Утро. Самое лучшее» 16+
08.00, 10.00, 13.00, 16.00, 19.00, 23.35 «Сегодня»
08.25, 10.35 Сериал «МОРСКИЕ ДЬЯВОЛЫ. ОСОБОЕ ЗАДАНИЕ» (S) 16+
13.25 «Чрезвычайное происшествие»
14.00 «Место встречи»
16.45 «За гранью» 16+
17.50 «ДНК» 16+
20.00 Премьера. Остросюжетный детектив «АУТСАЙДЕР» (S) 16+
22.00, 00.00 Боевик «НЕВСКИЙ. ТЕНЬ АРХИТЕКТОРА» (S) 16+
00.40 Олег Морозов в остросюжетном сериале «ОБЪЯВЛЕН В РОЗЫСК» 16+
04.35 «Их нравы» 0+

ДОМАШНИЙ
06.30 «6 кадров» 16+
06.35 «По делам несовершеннолетних» 16+
08.35 «Давай разведёмся!» 16+
09.35 «Тест на отцовство» 16+
11.40 «Понять. Простить» 16+
12.45 «Порча». «Лихо» 16+
13.15 «Знахарка» 16+
13.50 «Верну любимого» 16+
14.25 «Голоса ушедших душ» 16+
15.00 «САШИНО ДЕЛО» 16+
19.00 «ГРУЗ ПРОШЛОГО» 16+
23.00 «ВОСТОК – ЗАПАД» 16+
02.30 «Порча» 16+
02.55 «Знахарка» 16+
03.20 «Верну любимого» 16+
03.50 «Голоса ушедших душ» 16+
04.15 «Понять. Простить» 16+
05.05 «По делам несовершеннолетних» 16+

ЗВЕЗДА
05.00 «КАДЕТЫ». 3-я и 4-я серии 12+
07.00 Информационно-развлекательная программа «Сегодня утром» 12+
09.00, 13.00, 18.00, 20.30 Новости дня 16+
09.20, 00.55 «ДУМА О КОВПАКЕ». Телесериал. «НАБАТ» 12+
11.20, 21.15 «Открытый эфир». Ток-шоу 16+
13.20, 15.05 «КРОТ». 1-я – 4-я серии 16+
15.00 Военные новости 16+
18.20 «Специальный репортаж» 16+
18.55 «Подпольщики». Документальный сериал. «Они были первыми» 16+
19.40 «Загадки века с Сергеем Медведевым». Документальный сериал. «Спасение Романовых» 12+
22.55 «Между тем» с Наталией Метлиной 12+
23.20 «ВОСКРЕСНЫЙ ПАПА» 12+
02.30 «Алексей Косыгин. Ошибка реформатора». Документальный фильм 12+
03.30 «КРОТ». Телесериал. 1-я и 2-я серии 16+

14 март | Сишәмбе

ВГТРК ТАТАРСТАН
05.05, 06.05, 07.05, 08.05 «Вести-Татарстан. Погода»
05.35, 06.35, 07.35, 08.35 «Вести-Татарстан. Утро»
09.00 «Яңалыклар. Татарстан»
09.30 «Хәерле көн, Татарстан!»
14.30, 21.05 «Вести-Татарстан»

ТНВ ТАТАРСТАН – ЯҢА ГАСЫР
06.00, 07.10 «Манзара». Мәгълүмати-күңел ачу программасы 16+
07.00, 18.30, 20.30, 05.50 Татарстан хәбәрләре 16+
08.00, 14.30, 19.30, 21.30 Новости Татарстана 16+
08.10 «Здравствуйте!» 16+
09.00, 17.00 «КӨТЕЛМӘГӘН КУНАК». Телесериал 16+
10.00, 23.00 «ИДЕАЛЬНАЯ ЖЕНА». Телесериал 16+
11.00 «Азбука долголетия» 16+
11.15 «Память сердца» 16+
11.30, 16.30 «Татарлар» 12+
12.00, 22.10 «БӘХЕТ КЫЙПЫЛЧЫКЛАРЫ». Телесериал 12+
13.00 «Туган җир» 12+
13.30 «Юлчы» 16+
14.00 «Путь» 16+
14.15 «Не от мира сего...» 16+
14.45 «Моң чишмәсе» 16+
15.15 «Шаян ТВ» тәкъдим итә. «Төймә» 0+
16.00 «Ватандашлар» 16+
18.00 «Әдәби хәзинә» 16+
19.00 «Таяну ноктасы» 16+
20.00, 22.00 «Вызов 112» 16+
20.15 «Күчтәнәч» 0+
21.00 «Ватандашлар» 16+
00.00 «Видеоспорт» 16+
00.25 «Соотечественники». Мирсаит Султан-Галеев. Отец революции третьего мира 16+
00.50 «Здоровая семья: мама, папа и я» 12+
01.05 «Если хочешь быть здоровым» 16+
01.15 «Башваткыч» 12+
02.00 «Манзара». Мәгълүмати-күңел ачу программасы 16+
03.30 «Әдәби хәзинә» (субтитрлы) 16+
03.55 «Йөрәктән – йөрәккә» (субтитрлы) 16+
04.45 «Ком сәгате» 16+
05.35 «Оныта алмыйм...» Ретро-концерт 12+

ТНВ-ПЛАНЕТА
06.00, 13.05, 01.05 «Манзара». Мәгълүмати- күңел ачу программасы 16+
08.00 «Үткәннәр сагындыра» 12+
08.40, 23.05, 04.15 «Җырлыйк әле!» 12+
09.40 «Канун. Парламент. Җәмгыять» 16+
10.30, 20.30 «Халкым минем» 12+
11.00, 15.00, 18.00, 21.00, 00.00 «Яңалыклар» 16+
11.30 «Ватандашлар» 16+
12.05, 18.20, 21.25 «ЯЗМЫШЛАРДАН УЗМЫШ ЮК ИКӘН». Телевизион нәфис фильм 16+
15.30, 20.00 «Таяну ноктасы» 16+
16.00 «Әдәби хәзинә» (субтитрлы) 6+
16.30 «Шаян ТВ» тәкъдим итә... 6+
17.00 «Моң чишмәсе» 16+
17.30, 19.35, 00.40 «Татарлар» 12+
19.20, 22.20, 03.25 «Тибрәнә җыр дулкыннары» 12+
00.15 «Тамчы-шоу» 6+
02.50 «Караоке татарча» 12+
03.00 «Әдәби хәзинә» (субтитрлы) 6+
05.05 «Әй, язмыш, язмыш...» (субтитрлы) 12+

1 КАНАЛ
05.00 Телеканал «Доброе утро»
09.00 Новости (с субтитрами)
09.20 Премьера. «АнтиФейк» 16+
09.55 «Жить здорово!» 16+
10.45 Информационный канал 16+
12.00 Новости (с субтитрами)
12.15 Информационный канал 16+
15.00 Новости (с субтитрами)
15.15 Информационный канал 16+
16.00 «Мужское/Женское» 16+
16.50 Информационный канал 16+
18.00 Вечерние новости (с субтитрами)
18.20 Информационный канал 16+
21.00 «Время»
21.45 Премьера. «РАНЕВСКАЯ». Многосерийный фильм (S) 12+
22.45 «Большая игра» 16+
23.45 ПОДКАСТ.ЛАБ «Легкие деньги» 16+
00.25 ПОДКАСТ.ЛАБ «Все хотят летать» 16+
01.05 ПОДКАСТ.ЛАБ «20 лет спустя» 16+
01.45 ПОДКАСТ.ЛАБ «Пусть не говорят, пусть читают» 16+
02.25 ПОДКАСТ.ЛАБ «Секс при свете» 18+
03.00 Новости
03.05 ПОДКАСТ.ЛАБ «Неформат» 16+
03.40 ПОДКАСТ.ЛАБ «Креативные индустрии» 16+
04.15 ПОДКАСТ.ЛАБ «АстроУмные» 16+

РОССИЯ 1
05.00 «Утро России»
09.00 Местное время. Вести-Татарстан
09.30 «Утро России»
09.55 «О самом главном». Ток-шоу 12+
11.00, 14.00, 16.00, 20.00 Вести
11.30 «60 минут». Ток-шоу 12+
14.30 Местное время. Вести-Татарстан
14.55 «Кто против?» Ток-шоу 12+
16.30 Премьера. «Малахов» 16+
17.30 «60 минут». Ток-шоу 12+
21.05 Местное время. Вести-Татарстан
21.20 Русская серия. Премьера. Ирина Пегова, Ярослав Бойко, Наталья Гудкова. «АКУШЕРКА. НОВЫЕ СЕРИИ» 16+
23.25 «Вечер с Владимиром Соловьёвым» 12+
02.05 Детективный телесериал «ДУЭТ ПО ПРАВУ» 12+
03.55 Анна Гарнова, Илья Шакунов, Никита Панфилов, Борис Невзоров, Екатерина Кистень. «ЛИЧНОЕ ДЕЛО» 12+

МАТЧ ТВ
06.00, 13.45 «Спортивный век» 12+
06.30 «Что по спорту? Вологда» 12+
07.00, 10.00, 12.20, 14.15, 16.20 Новости
07.05, 16.25, 22.10, 01.00 Все на Матч! Прямой эфир
10.05, 12.00 Специальный репортаж 12+
10.25 Смешанные единоборства. UFC. Пётр Ян против Мераба Двалишвили. Александр Волков против Александра Романова. Трансляция из США 16+
11.30 «Ты в бане!» 12+
12.25 «Есть тема!» Прямой эфир
14.20 Еврофутбол. Обзор 0+
15.20 Профессиональный бокс. Тим Цзю против Тони Харрисона. Бой за титул чемпиона мира по версии WBO. Трансляция из Австралии 16+
17.00 Футбол. FONBET Кубок России. «Акрон» (Тольятти) – «Локомотив» (Москва). Прямая трансляция
19.30 Футбол. FONBET Кубок России. «Спартак» (Москва) – «Урал» (Екатеринбург). Прямая трансляция
22.45 Футбол. Лига чемпионов. 1/8 финала. «Манчестер Сити» (Англия) – «Лейпциг» (Германия). Прямая трансляция
01.55 Футбол. Лига чемпионов. 1/8 финала. «Порту» (Португалия) – «Интер» (Италия) 0+
03.55 Новости 0+
04.00 Художественная гимнастика. Гран-при. Трансляция из Москвы 0+

НТВ
04.55 Сериал «МОСКВА. ТРИ ВОКЗАЛА» (S) 16+
06.30 «Утро. Самое лучшее» 16+
08.00, 10.00, 13.00, 16.00, 19.00, 23.35 «Сегодня»
08.25, 10.35 Сериал «МОРСКИЕ ДЬЯВОЛЫ. ОСОБОЕ ЗАДАНИЕ» (S) 16+
13.25 «Чрезвычайное происшествие»
14.00 «Место встречи»
16.45 «За гранью» 16+
17.50 «ДНК» 16+
20.00 Премьера. Остросюжетный детектив «АУТСАЙДЕР» (S) 16+
22.00, 00.00 Боевик «НЕВСКИЙ. ТЕНЬ АРХИТЕКТОРА» (S) 16+
00.40 «ОБЪЯВЛЕН В РОЗЫСК» 16+
04.35 «Их нравы» 0+

ДОМАШНИЙ
06.30 «По делам несовершеннолетних» 16+
08.25 «Давай разведёмся!» 16+
09.30 «Тест на отцовство» 16+
11.35 «Понять. Простить» 16+
12.40 «Порча». «Бонбоньерка» 16+
13.10 «Знахарка» 16+
13.45 «Верну любимого» 16+
14.20 «Голоса ушедших душ» 16+
14.55 «МОЖЕШЬ МНЕ ВЕРИТЬ» 16+
19.00 «СЛОВНО НЕ БЫЛО РАЗЛУКИ» 16+
23.05 «ВОСТОК – ЗАПАД» 16+
02.35 «Порча» 16+
03.00 «Знахарка» 16+
03.25 «Верну любимого» 16+
03.55 «Голоса ушедших душ» 16+
04.20 «6 кадров» 16+
04.25 «Понять. Простить» 16+
05.15 «По делам несовершеннолетних» 16+

ЗВЕЗДА
05.10 «КРОТ». Телесериал. 3-я и 4-я серии 16+
07.00 Информационно-развлекательная программа «Сегодня утром» 12+
09.00, 13.00, 18.00, 20.30 Новости дня 16+
09.20, 01.10 «ДУМА О КОВПАКЕ». Телесериал. «БУРАН» 12+
11.20, 21.15 «Открытый эфир». Ток-шоу 16+
13.20, 15.05 «КРОТ». Телесериал. 5-я – 8-я серии 16+
15.00 Военные новости 16+
18.20 «Специальный репортаж» 16+
18.55 «Подпольщики». Документальный сериал. «Маршрут спасения» 16+
19.40 «Улика из прошлого» 16+
22.55 «Между тем» с Наталией Метлиной 12+
23.20 «ВПЕРВЫЕ ЗАМУЖЕМ» 12+
02.45 «Зафронтовые разведчики». Документальный сериал 16+
03.30 «КРОТ». Телесериал. 5-я и 6-я серии 16+

КОТЛЫЙБЫЗ!

Һөнәри эшчәнлектәге казанышлары һәм актив иҗтимагый хезмәте өчен Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Советы аппараты җитәкчесе **Әфләтунова** Роза Егоровна, халыкка социаль хезмәт күрсәтү өлкәсендәге казанышлары һәм актив иҗтимагый эшчәнлеге өчен «МИН БУЛДЫРАМ» мөмкинлекләре чикле кешеләргә ярдәм итү автоном коммерциячел булмаган оешмасының дәвалау физкультурасы буенча инструкторы **Ильясов**а Гайшә Заһит кызы **Татарстан Республикасының «Фидакарь хезмәт өчен» медале** белән бүләкләнде.

* * *

Татарстан Республикасының социаль-икътисадый потенциалын ныгытуга зур өлеш кертүе һәм күпьеллык нәтиҗәле хезмәте өчен «Бөгелмә тегү фабрикасы» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте тегүче-мотористы **Кудряшова** Мария Васильевна **«Татарстан Автономияле Совет Социалистик Республикасы төзелүгә 100 ел»** медале белән бүләкләнде.

* * *

«Россия Федерациясенең селекция казанышларын сынау һәм саклау буенча дәүләт комиссиясе» федераль дәүләт бюджет учреждениесенең Татарстан Республикасы буенча филиалы сортларны сынау буенча Буа дәүләт участогы мөдире **Төхвәтуллин** Миңнулла Абдрахман улына **«Татарстан Республикасының атказанган агрономы»** дигән мактаулы исем бирелде.

* * *

«Агроторгсервис» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыятенең машина белән сыер саву өлкән операторы (Татарстан Республикасының Питрәч районы) **Алексеева** Лариса Григорьевнага, «Олы Кариле» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте терлекчесе (Татарстан Республикасының Кама Тамагы районы) **Вәлиев** Хәниф Хафиз улына **«Татарстан Республикасының атказанган терлекчесе»** дигән мактаулы исем бирелде.

* * *

«Хузангай» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте механизаторы (Татарстан Республикасының Әлки районы) **Иванов** Александр Ивановичка **«Татарстан Республикасының атказанган авыл хуҗалыгы механизаторы»** дигән мактаулы исем бирелде.

* * *

«Мамадыш балык заводы» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте директоры **Грушев** Егор Григорьевичка, «ЧАЛЛЫ ИКМӘГЕ» акционер җәмгыятенең тоз эремәсе фазасында камыр куючы **Кабанова** Ләйсирә Мөбарәкҗан кызына, «РМ АГРО» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте баш бухгалтеры **Глухова** Гөлнур Раиф кызына, «ЧАЛЛЫ ИКМӘГЕ» акционер җәмгыятенең күмәч цехы смена өлкән хезмәткәре **Клинова** Валентина Ивановнага, «Таткрахмалпатока» акционер җәмгыятенең салат цехы башлыгы **Лядащева** Галина Анатольевнага, «Торос Сөт» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыятенең сөтне пастеризацияләү аппаратчысы **Сосунова** Валентина Алексеевнага **«Татарстан Республикасының атказанган азык-төлек сәнәгате хезмәткәре»** дигән мактаулы исем бирелде.

* * *

«Сәйдәшев исемендәге авыл хуҗалыгы предприятиесе» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыятенең баш икътисадчысы (Татарстан Республикасының Тукай районы) **Дәүләтгәрәева** Лена Гыйздәтулла кызына, «ЗӘЙ» агрофирмасы җаваплылыгы чикләнгән җәмгыятенең «Дүрт-Мунча» товарлыклы-сөтчелек фермасы мөдире (Татарстан Республикасының Зәй районы) **Захаров** Геннадий Васильевичка, «Идиәтуллина Мөршидә Гарәфи кызы» крестьян (фермер) хуҗалыгы башлыгы (Татарстан Республикасының Буа районы) **Идиәтуллина** Мөршидә Гарәфи кызына, Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгының Татарстан Республикасы Буа муниципаль районындагы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек идарәсе җитештерү бүлеге өлкән белгече **Исхаков** Равил Идиятулла улына, «Красная Заря» авыл хуҗалыгы җитештерү кооперативы баш инженеры (Татарстан Республикасының Биектау районы) **Корчагин** Евгений Николаевичка, «Мөхәммәтов Рафис Вагыйзь улы» крестьян (фермер) хуҗалыгы башлыгы (Татарстан Республикасының Спас районы) **Мөхәммәтов** Рафис Вагыйзь улына, «Нуруллин Рәфгать Әхәт улы» крестьян (фермер) хуҗалыгы башлыгы (Татарстан Республикасының Чистай районы) **Нуруллин** Рәфгать Әхәт улына, «Рәхмәтуллин Айрат Хөсәен улы» крестьян (фермер) хуҗалыгы башлыгы (Татарстан Республикасының Чистай районы) **Рәхмәтуллин** Айрат Хөсәен улына **«Татарстан Республикасының атказанган авыл хуҗалыгы хезмәткәре»** дигән мактаулы исем бирелде.

Динә ГЫЙЛАҖИЕВА

БӨЕР: БУЛМАСЫН ТӨЕР

2006 елдан бирле март аеның икенче пәнҗешәмбесендә Дөньякүләм бөер авыруларына каршы көрәш көне билгеләп үтелә. Организмыбызны даими рәвештә чистартып торучы иң мөһим органнарның берсе ул. Аны ничек сакларга? БАДлар ярдәмендә бөер чистарту дөресме?

Табиб-нефролог Ильмира ГАЛИНА бөергә бәйле сорауларыбызга ачыклык кертте.

:: Бөер авырулары бүген киң таралганмы?

– Бүген Җир шарында яшәүчеләрнең 15 проценты хроник бөер авыруларыннан интегә. Кызганыч, бу сан елдан-ел арта бара. Үлем-китем, инвалидлыкка китергән иң мәкерле чирләрнең берсе санала ул. Элегрәк бөер авыруларына әллә ни зур игътибар бирелми иде. Хәзер еш очраганлыктан, аның турында еш сөйләргә туры килә. Соңгы арада коронавирус белән авырып терелүчеләр арасында да бөер авыруларыннан интегүчеләр саны артты. Гипертония, шикәр чире авырулары да бөерләргә зыян сала. Бөер авыруларын тиз генә ачыклыйм димә. Ник дигәндә, башлангыч чорда алар бернинди билгеләрсез уза. Бөердә хилафлык барлыгы еш кына диспансеризация яки профилактик медицина тикшерүе барышында гына ачыклана.

:: Шулай да организмдагы кайсы үзгәреш, билгеләр бөерләрдә хилафлык барлыгы турында сөйли?

– Иң беренче чиратта, бил авыртса, игътибарлы булырга кирәк. Ул бер яктан гына да, берьюлы ике яктан да борчырга мөмкин. Бөер авыртканда, тән температурасы 37–38 градуска кадәр күтәрелә, йөз шешенә, иртән күз төпләре карала, аяклар шешенә, кан басымы күтәрелә, кеше хәлсезләнүдән интегә. Авыз кибү, төнлә кече йомыш белән еш йөрү, бәвелнең төсе һәм исе үзгәрү дә бөердәге хилафлыклар барлыгы турында кисәтә.

:: Бөер авыруы ничек ачыклана?

– Бөер авыруларын ачыклау өчен, гомуми, биохимик кан анализлары, бәвел анализы тапшырырга кирәк. Алар начар чыкса, табиб тагын да җентеклерәк тикшерелү узарга җибәрәчәк.

:: Бөер авыруы коронавирустан соңгы өзлегү дә була ала, диләр...

– Дөрестән дә, пандемиядән соң бөер авыруларыннан интегүчеләр саны артты. Араларында олысы да, кечесе дә бар. Бу – нигездә, коронавирус вакытында күп дару эчү нәтиҗәсе.

:: Бөерне нәрсәләр сафтан чыгара?

– Чамадан тыш күп дару, БАД эчү бөерләр өчен зур сынауга әйләнә. Күптән түгел генә безгә, ярдәм сорап, бер кыз мөрәҗәгать иткән иде. Кирәксә-кирәкмәсә дару эчүе аркасында, бөере борчый башлаган аның. Тычкан бизгәге авыруы, сыйфатсыз исерткеч эчемлек тә бөерләргә зур зыян сала. Алда телгә алган әйберләр бөерләргә кисәк кенә бәрә. Шикәр чире, югары кан басымы, хроник цистит исә әлеге мөһим органны акрынлап җимерә.

:: Бүген төрле БАД, үлән чәйләре ярдәмендә бөерне чистарту да популярлашып китте. Мондый чистарының файдасы күбрәкме, зыянымы?

– Бөерләрне чистарту өчен билгеләнгән БАДларны эчәргә киңәш итмәс идем. Ник дигәндә, бу препаратларның файдасы фәнни яктан расланмаган. Үлән һәм төрле төнәтмәләргә килгәндә, алар бу очракта дөрестән дә файдалы. Бөерләргә бигрәк тә нарат җиләге, мүк җиләге, карлыган, гөлҗимеш төнәтмәсе, чәйләре файдалы. Алар сидекне бик яхшы куа, ялкынсынуга каршы иң нәтиҗәле чараларның берсе санала. Әмма үләннәр белән эш иткәндә дә сак булырга кирәк. Аларны табиб белән киңәшләшкәч кенә куллану хәерле.

:: Диализ алган кеше озак яшәми дигән фикер бар. Бу сүзләр дөреслеккә туры киләме?

– Бу – уйдырма. Диализдагы кешеләр егерме ел да, утыз ел да яшәргә мөмкин. Иң мөһиме – ул бу процедураны калдырмыйча, вакытында ясатып барырга, табиб әйткәннәргә колак салырга тиеш. Ясалма бөер ролен башкаручы диализ канны азот алмашы вакытында бүленеп чыккан токсин һәм шлаклардан чистарта. Диализ атнага өч тапкыр, дүрт сәгать дәвамында ясала.

vk.com

БӨЕР АВЫРУЛАРЫН БУЛДЫРМАУ ӨЧЕН КИҢӘШЛӘР

▶ Нәселендә бөер авыруыннан азапланучылар булган кеше һәрчак аң булырга тиеш. Иң беренче эш итеп, нефрологка барырга, бу төр авыруларның сизгә ни дәрәҗәдә янавын ачыкларга кирәк.

▶ Шикәр белән мавыгу да юньлегә илтми.

▶ Спорт белән шөгыльләнү, һәрчак хәрәкәттә булу, иртән күнегүләр ясау кече очада кан оешып торырга ирек бирми. Димәк, бөер авырулары килеп чыгу ихтималы да бермә-бер кими.

▶ Кан басымын да һәрчак контрольдә тотыгыз. Әгәр кеше 150/90 күрсәткечле югары кан басымы белән яши һәм үзен яхшы хис итә икән, димәк, чаң сугарга җирлек бар. Мондый югары кан басымы вакытында баш авыртырга, күңел болганырга тиеш. Шуңа күрә андый чакта, кичекмәстән табибка мөрәҗәгать итеп, тиз арада чарасын күрергә кирәк.

▶ БАДлар белән мавыгу, кирәксә-кирәкмәсә дару эчү, вируслы авыруларны үз белдегең белән дәвалау бөерләр өчен шулай ук куркыныч.

▶ Бөер авыруларын кисәтү өчен, ел саен диспансеризация, медицина тикшеренүе узып торырга кирәк.

Киңәш-табыш

Арыганлыкны ничек җиңәргә?

Моның өчен 2 әфлисунны юып, кабыгын чистартып киптерегез дә, шуны төеп, 2 аш кашыгы зәйтүн мае салып береаз тотыгыз. Аннары шуны җылы сулы ваннага салыгыз да шул суда ятып торыгыз. Хәл керер.

Баш авыртканда...

Әгәр башыгыз бер генә урыннан авырта икән, димәк, парлы ванна кирәк. Моның өчен чәйнектә яки чүмечтә су җылытыгыз (яртылаш алма серкәсе кушып). Кайнау хәленә килеп, пар чыга башлагач, зур йомшак сөлге белән башыгыздан капланып, пар өстенә иелегез һәм шул җылы парны әчкә сулагыз. Бер сеанста якынча 50 сулыш алу кирәк. Күбрәк тә мөмкин. Шуннан соң, гадәттә, баш авырту бетә, һәрхәлдә, сизелерлек кими.

Кан әйләнешен яхшыртабыз



Энҗе әгъзаларда кан әйләнешен яхшырту өчен уклау да ярый. Атнага бер мәртәбә 15–20 минут идәндә яланаяк уклау тәгәрәтергә кирәк. Моны аш бүлмәсендә эш арасында да эшләп була. Шунда ук тынычландыргыч күнегүләр дә ясарга мөмкин. Мәсәлән, тыры басып, аякларны җилкә киңлегендә куеп, ике кулны алга сузасың. Өчкә кадәр санап, «өч» дигәндә кулларны төшерәсең. Аннан соң урындыкка утырып, күзләрне йомып, 1–2 минут торасың. Бу күнегүне дә эш арасында тәнәфес урынына башкарырга мөмкин. Үзеңне шулай тынычландырырга өйрәнсәң, күп авыруларны булдырмый калырга мөмкин.

Белсәң, зыян итмәс

ЙОМЫРКА ФАЙДАСЫ

✓ Йомырка кетәклектән алып кергән көнендә үк ашаганда күбрәк файдалы.

✓ Йомырканы салкынча урында яисә тоз эчендә сакларга кирәк.

✓ Йомырканың сарысы аеруча файдалы. Ул тулысынча диярлек эшкәртелеп, файдалы матдәләргә бүленеп бетә. Йөрәкне, баш миен һәм тәнне ныгыта; күкрәкне, үпкәләрнең эшчәнлеген яхшырта; ашказаны, эчәк, сидек куыгы авыруларын дәвалый; күп кан югалткан кешеләрнең хәлен яхшырта.

✓ Тавышны чистарту өчен, сидек куыгы эчтән янганда чи йомырка сарысы эчәләр. Ләкин чи йомырка сарысының зарары да бар: бөерләргә таш утырырга, тәнгә бетчәләр чыгарга мөмкин.

✓ Йомырканы ярым пешкән килеш ашарга кирәк. Моның өчен аны кайнар суга салгач, 100гә хәтле санарга кирәк. Шул чакта йомырка пешәр-пешмәс була. Ә иң яхшысы – йомырканы сытып, суда яисә сөттә пешерү.

✓ Тән пешкәндә чи йомырка сөртергә кирәк. Ул аны тиз төзәтә.

Гөлнара ЗИННӘТУЛЛИНА

АЕРМАСЫ БАР

Бакчасы булганнарның да тәрәзә төбендә кыяр, помидор, борыч үстереп караганы бардыр. Тик аның үз тәртибе бар.Агроном-селекционер Светлана МИХАЙЛОВА укучыларны кызыксындырган сорауларга җавап бирде.

vk.com

1 Тәрәзә төбенә бал корты белән серкәләнә торган кыяр утыртырга ярыймы?

– Ярый, тик аларны үзегезгә кул белән серкәләндерергә туры килә. «Ир» чәчәк серкәчләренә мамык таякчыклар белән кагыласыз да аннары «хатын» чәчәккә тидерәсез. Моның әлләни катлаулылыгы юк, бары «ир» белән «хатын» чәчәкләрне генә аера белергә кирәк.

2 Бер тәрәзә төбендә ачы һәм баллы борыч үстерергә ярыймы?

– Бакчада ачы һәм баллы борычларны янәшә утыртмаска киңәш ителә. Үзлектән серкәләнә торган булсалар да, аларга бал корты белән шөпшәләр дә кунарга мөмкин. Әгәр бөҗәкләр ачы борычта «кунак» булганнан соң, эре баллы борычка кунсалар, аның ачы булуы бар. Өйдә бал корты һәм шөпшәләр булмаганлыктан, аларны янәшә дә утыртырга мөмкин.

3 Тәрәзә төбендә озын сабаклы помидорлар үстереп буламы?

– Урын җитәрлек булганда биек булып үсә торган помидорларны да өйдә үстерергә була. Андый томатларны куләме 10 литрдан да ким булмаган зур чүлмәкләргә утыртырга кирәк. Гадәттә, биек үсә торган помидорлар яктылык ярата торган булалар, шунлыктан көз уртасыннан яз уртасына кадәр фитолампалар кулланырга кирәк.

4 Тәрәзә төбенә нинди сорт һәм гибридларны утыртырга мөмкин?

– Кыяр: Маринда F1, Онежский F1, Маша F1, Легенда F1, Сережа F1.

Помидор: Балконное чудо, Комнатный сюрприз, Жемчужина красная, Жемчужина желтая, Японский комнатный, Бонсай, Бонсай микро F1, Черри Пигмей, Пиноккио, Минибел. Шулай ук аска таба асылынып үсә торган сортлар бар: Черри, Перуанский домашний, Ильди.

Борыч: сары Патио-Иво, калын тышчалы ачык кызыл Калифорнийское чудо, шәмәхә Ода. Шулай ук Юпитер F1 гибриды, уртача иртә өлгерә торган Ласточка, Винни-Пух, Подарок Молдовы.

Кирәге чыгар

Ит сайлый беләсеңме?

✓ Итнең өслеген яхшылап карагыз. Аның өслеге бераз җилләгән һәм кибеп киткән төсле икән, шикләнмәгез. Әлеге «кабык» аны кибүдән саклый. Ә итнең өсте юеш һәм сул эчендә ята икән, алмавыгыз хәерле.

✓Май катламы ак төстә булганын сайлагыз. Бу – мал яшь булган һәм ите йомшак дигән сүз. Итнең мае сары икән, ул каты булачак.

✓ Йомшак җиренә бармагыгыз белән басып карагыз. Батып киткән өлеше яңадан үз хәленә кайта икән, димәк, мал яңа чалынган, әгәр бармак эзе озак сакланса, алмавын хәерле.

✓ Төсенә дә игътибар итегез. Сыер ите – кызыл, ә бозаунысы алсурак төстә була. Үзегез алырга җыенган кисәктә бераз кисем ясап күрсәтүләрен сорарга кыенсынмагыз.

✓ Итне иснәп карагыз. Ацетон, серкә яки әчкелтем ис килә икән, очсыз дип, мондый итне ала күрмәгез.

✓ Туралган ит түшкәләрендә ветеринария хезмәтенең мөһере тора. Сатучының намуслылыгында шикләнсәгез, иткә ветеринария таныклыгын сорагыз. Аның сатуга тапшыру вакыты кичәгедән дә элеккерәк булмаска тиеш.

Тәмле булсын!

БАЛАН БӘЛЕШЕ

Рәмзия ХАҖИЕВА рецепты

250 г ак майны туңдыргычтан алдым да шул каты килеш угычтан удым, онга бер чәй кашыгы тутырып кабартмачы (разрыхлитель), 3 аш кашыгы шикәр комы, бер чеметем тоз салып, май белән бутадым. Шуңа 2 аш кашыгы каймак, бер йомырка, һәм 30–40 г чамасы сап-салкын су салып, йомшак, ләкин кулга ябышмый торган камыр басып, ял иттерергә салкынга куйдым.

Эчлек өчен 500 г туң баланга 5 аш кашыгы манный, 2 аш кашыгы крахмал, 400 г шикәр комы салып болгаттым. Бәлеш ясап, алдан 180 градуста җылытылган мичкә 25–30 минутка тыктым.

Исеңдә тот!

Аягың юешләнмәсен

Яз көне аяк киемнәренә аеруча игътибарлы булырга кирәк. Дымланып интектермәсен дисәгез, аяк киеме кибетләрендә сатыла торган махсус спрей һәм су үткәрми торган балавызлар кулланыгыз.

Спрейны күн, замша, нубук өчен кулланырга була. Аны сиптергәндә, аяк киеме чиста һәм коры булырга тиеш. Спрейны аяк киеменә сеңми башлаганчы сиптертергә кирәк. Аннары аны киптерергә куясың, моны урамга чыгар алдыннан 6 сәгать алдан эшләргә кирәк.

Балавыз исә шома күн өчен туры килә. Аның карасы һәм төссезе була. Аны чиста һәм коры аяк киеменең бөтен өслегенә щетка белән сөртеп чыгасы. Болай эшләгәндә аяк киеменә пычрак та бик ирми, юешләнми һәм күне бик затлы, матур булып күренә.

Укучы киңәше

СӨТ БЕЛӘН ЙОД ЯРАТА

Помидорны әлеге ысул белән тукландыра башлаганнан соң уңыш иртәрәк өлгергәнен һәм күбрәк булганын сиздем.

3 л суга 250 мл сөт салып яхшылап болгатасы. Аңа 5–6 тамчы йод салып, тагын болгатып, 1–2 сәгать тотарга һәм аннары помидор кәлшәләре төбенә сибәргә. Әлеге катнашманы орлык чәчүгә түгел, ә аерым савытларга күчереп утырткач сибегез.

А. ГАЛИМОВ. Кукмара

Белеп тор!

КӘЕФ КҮТӘРҮНЕҢ 5 ЫСУЛЫ

Көтелмәгән хәл, якын кешең белән низагка керү, чәй эчеп утырганда киемеңә нидер төшеп аны таплау – болар барысы да кәеф кырылуга сәбәп булырга мөмкин. Әмма моннан бик тиз котылуның берничә ысулы бар.

• Берәр тәмле яки баллы әйбер ашагыз. Баллы ризык «бәхет» гормоннарын – серотонин белән дофаминны уятып җибәрә һәм кәефегез күтәрелүен сизәрсез.

• Аз-азлап йотып, җылы су эчегез. Бу баш миен куңелсез уйлардан арындырып җибәргәндәй итәр.

• Битегезне салкын су белән юып алыгыз. Ул тынычланырга һәм кәефегез күтәрелүгә сәбәпче булыр.

• Урамда нинди һава торышы булуга карамастан, 5–10 минут булса да саф һавада йөреп керегез. Мөмкинлек булса, табигатьтә йөрсәгез, тагын да яхшырак. Бу уйларыгызга башка юнәлеш алырга ярдәм итәр.

• Моңсу түгел, ә мәнә нәкъ мәнә кәеф күтәрә торган җырлар тыңлагыз. Тыңлау мөмкинлеге булмаса, күңелегездән булса да исегезгә төшереп алыгыз.

БҮГЕННӘН ӘЗЕРЛӘНӘСЕ

Мөселманнарның иң изге ае – рамазан ае башланырга санаулы гына көннәр калып бара. Быел ул, 23 мартта башланып, 20 апрельгә кадәр дәвам итәчәк. 22 март көнне мәчетләрдә беренче тәравих намазы укылачак. Рамазан аен ничек каршы алырга? Уразага ничек әзерләнергә?

Укучыларыбыз игътибарына «Иман нуры» мәчетенең икенче имам-хатыйбы Әхмәт хәзрәт ФӘЙЗУЛЛИНның бу уңайдан киңәшләрен тәкъдим итәбез.

– Рамазан ае алдыннан килүче шәгъбан ае – рамазанга әзерләнә торган ай ул. Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм иң күп уразаны шәгъбан аенда тоткан. Хәдистән аңлашылганча, Үсәмә бине Зәед радыяллаһу ганһе пәйгамбәребезгә: «Әй Аллаһның Расүле! Шәгъбан аеннан кала, башка айларда синең шулкадәр ураза тотканыңны күргәнем булмады», – дип әйткән. Пәйгамбәребез аңа: «Рәҗәб белән рамазан айлары арасында булган бу ай хакында кешеләр гафил. Бу айда кылган гамәлләр Галәмнәрнең Раббысы хозурына күтәреләләр. Шуңа да гамәлләрем күтәрелгән вакытта уразада булуымны телим», – дип җавап биргән. Димәк, рамазан ае кергәнче үк уразаны тота башлауны шушы айга әзерләнүнең иң яхшы ысулларының берсе дип әйтеп була. Рамазан аена бик аз вакыт калган булса да, аның килүенә мөмкин кадәр яхшырак әзерләнергә кирәк.

1 Беренчедән, ураза турында ышанычлы белем алырга тырышыгыз. Яхшы мәгълүмат табыгыз яки белемле кешеләрдән сорагыз. Ураза дөреслеге өчен нәрсә кирәк, аны нәрсә боза? Кем ураза тотарга тиеш, кем аны тотудан азат? Шушы мөһим сорауларга җавап табарга тырышыгыз.

2 Дини әдәбиятны күбрәк укыгыз. Рамазан аеның мөһимлеге һәм әһәмияте, аның кыйммәтләре, фазыйләтләре турында вәгазьләр тыңлагыз.

3 Коръән укый беләсез икән, аны күбрәк укыгыз. Мөгълүм булганча, тәкъва кешеләр шәгъбан һәм рамазан айларында Коръән укуны арттырганнар.

vk.com

4 Шәгъбан аенда ким дигәндә берничә көн өстәмә ураза тотарга тырышыгыз. Монда бик күп файда бар, һәм шулай итеп, сез әкренләп үзегезне, тәнегезне фарыз булган ураза режимына көйләячәксез.

5 Әгәр дә сезнең узган рамазан аеннан калган ураза бурычлары бар икән, киләсе рамазан аена кадәр аларны тотып бетерергә тырышыгыз. Ләкин бу, бөтен калган уразаларны да тотып бетерә алмасагыз, сез якынлашучы рамазан аендагы уразаны тотмаска тиеш дигән сүз түгел.

6 Күптән түгел җитди авыру кичергән булсагыз яки сәламәтлеккә бәйле проблемалар булса, ышанычлы табиб белән ураза тоту хакында киңәшләшегез. Аллаһы Тәгалә кешедән чиксез ашкыну таләп итми, бу сәламәтлеккә зыян китерә ала. Сәламәтлегебез – безгә ышанып тапшырылган әманәт. Без моның өчен җаваплы булачакбыз. Бу шулай ук йөкле һәм имезүче хатын-кызларга да кагыла.

7 Начар гадәтләрдән баш тартырга тырышыгыз. Төннәрне социаль челтәрләрдә үткәрмәгез, көндәлек тәртипне дөрес тотыгыз. Иртә йокларга ятып, иртә тору, саф һәм сыйфатлы ризык ашау мөһим. Шулай итеп, сез ураза алдыннан сәламәтлегегезне ныгытачаксыз.

8 Яла ягу, ялганлау яки алдау кебек явызлыклар – тел белән эшләнелә торган начар гамәлләрнең берничәсе генә. Ул тел афәтләреннән имин булырга кирәк, чөнки алар аркасында тоткан уразаның савабы хәтта юкка чыгарга да мөмкин. Пәйгамбәребез Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләм: «Ялган, сүгенү сүзләрен, ялган антны калдырмаган кешенең уразасы Аллаһка кирәк түгел, Аллаһ аның ураза тотуына мохтаҗ түгел», – дигән. Шулай ук Рәсүлуллаһ салләллаһу галәйһи вә сәлләм әйтте: «Ураза уттан калкан булып тора. Бу калкан яла ягу белән җимерелер. Ураза тоткан кеше каты һәм начар сүзләр әйтмәсен, шуның белән наданлык күрсәтер. Әгәр дә кемдер аның белән бәхәсләшә башласа, ул әйтсен: «Мин ураза тотам!» (Бохари). Әгәр шундый тел афәтләреннән рамазан аена кадәр котыла алсак, рамазан аендагы ураза һәм гыйбадәтләрнең кабул ителү мөмкинлеге артыр, иншәә Аллаһ.

КЕМНӘР ТОТАРГА ТИЕШ?

☑ Ураза балигълыкка ирешкән, үз акылында булган һәрбер мөселман ир һәм хатын-кызга фарыз кылынган, ягъни тиешле.

КЕМНӘР ТОТАРГА ТИЕШ ТҮГЕЛ?

☑ Хатын-кызларга күрем вакытында ураза тоту рөхсәт ителми, тыелган. Алар калган көннәрен рамазан аеннан соң тотып бетерергә тиеш.

Татарстан Диния нәзарәтенең матбугат үзәге:
– «Шура» журналына язылып булмый, чөнки ул имамнар өчен ярдәмлек буларак нәшер ителә. Ләкин «Хозур» нәшрияты кибетендә ул сатуда бар.

Укучы сүзе

«ИСТӘЛЕККӘ – ТАКТА» ЯЗМАСЫНА КАЙТАВАЗ

Саткач, ала инде.

Миләүшә ШӘЙДУЛЛИНА

***

Нишләп сатканнар соң? Юкмыни бездә татар эшмәкәрләре?

Рафис ХӘКИМОВ

***

Татар булмагач, билгеле, бетәрә инде татар рухын.

Дамира САБИРОВА

«КИТМИ КАЛГАННАР» ЯЗМАСЫНА КАЙТАВАЗ

...Тиз арада авылларны торгызу эшенә тотынмасалар, хәл бик аяныч. Илнең нигезе – авыл. Анда эш юк, дигән сүз дөрес сәбәп түгел. Авылда яшәп тә, башка җиргә йөреп эшләргә була. Шәһәрдә яшәгәннәр дә әллә кайларга китеп эшләп йөри. Хәзер авылда да бөтен шартларны тудырырга мөмкин. Моның өчен бер генә нәрсә – туып-үскән авылны, туган җирне, хезмәтне яратырга кирәк. Кызганыч, балаларга шуны өйрәтә алмадык, ахры...

Лариса ӘХМӘТШИНА

***

...Гомер иткән авыллары бит. Йөрәк әрни инде. Карамыйлар авылларны. Авылларны эшсез калдырып, хөкүмәт шундый дәрәҗәгә төшерде. Адәм баласының көн күрәсе бар.

Зөлфия ГАЛИМОВА

***

...Һәрбер авылны да шушы әбиләр язмышы көтә. Илдә сәясәт шундый.

Айнур НАСЫЙБУЛЛИНА

Ник кимегән?

Миңа – 80, ирем Филсургә – 84 яшь. Февраль аенда иремнең пенсиясе 2500 сумга кимрәк килде. Миңа районда, табышыгыз арткан, бабай сезне карый, шуңа күрә бу акчаны сезгә өстәгәннәр, дип аңлаттылар. Бу безнең районда гына шулаймы? Мондый хәлне бер дә ишеткән юк. Ни өчен бабайның акчасын киметкәннәр?

Хәзинә ШӘМСЕТДИНОВА.
Буа районы Кырык Садак авылы

Россия Социаль фондының Татарстан буенча бүлеге:
– Барысы да дөрес. Сез сораган 2500 сум ул – гаиләдәге ир яки хатынның икенчесенең тәрбиясендә булганы өчен, картлык буенча иминият пенсиясенә билгеләнгән түләү. Федераль Закон буенча «иждивенец» булып тулысынча туендыручысы карамагында яки табышы яшәү өчен төп чыганак булучыдан ярдәм алган гаилә әгъзасы санала. Сезнең иригез белән яшәү чыганагы – картлык буенча иминият пенсияләре. Быелның 1 гыйнварыннан иминият пенсияләре 4,8 процентка индексацияләнде, шул исәптән түләү күләме дә. Хәзер ул 7567 сум 33 тиенне тәшкил итә. 80 яшьлек пенсионерларга аның күләме ике мәртәбә арта, ул – аена 15134 сум 66 тиен. Сезнең пенсияләр арасында аерма зур түгел. Сез – «иждивенец», ә иригез туендыручы дип саналмый. Мөгаен, нәкъ менә шуңа күрә «иждивенец» өчен түләү туктаталып, иригез пенсиясе февральдән кимегәндер.

Тулырак мәгълүматны 8-800-1-00000-1 телефонына шалтыратып алырга мөмкин.

Сәрия МИФТАХОВА әзерләде

ЭШНЕҢ ХУҖАСЫ ЮК

Кеше чакырып өй җыештыртуның ояты юк! Бүген хуҗабикәләрнең күбесе шул фикердә. Саннар да бу сүзләрнең хаклыгын раслый. Бер ел эчендә Россиядә клининг хезмәтенә сорау 38 процентка арткан. «Бер сәгатькә ир» эзләүчеләр саны да күбәйгән. Йорттагы тузанны кем сөртергә тиеш тә чүкеч кем кулында? «ВТ» хәбәрчесе шул сорауларга ачыклык кертергә тырышты.

pinterest.com

Авыл да калышмый

«Авито.Хезмәтләр» сервисыннан алынган мәгълүматларга караганда, бер ел эчендә Россиядә клининг, ягъни җыештыру хезмәтенә сорау 38 процентка арткан. Кеше чакырып өй җыештыртырга яратучылар иң күп яшәгән шәһәрләр рейтингының беренче өчлегенә Красноярск, Самара, Екатеринбург кергән. Бу хезмәт Казанда да популярлаша бара. Әйтик, ел башыннан бирле генә дә башкалада мондый хезмәттән файдаланучылар 39 процентка арткан.

Кешеләр белгечләргә йортын юдырып кына калмыйча, берочтан башка вак-төяк мәшәкатьләрне дә эшләтергә тырыша икән. Шул сәбәпле бер ел эчендә илдә келәм (91 процентка арткан), йомшак җиһаз чистарту (49 процентка), ремонттан соң өй җыештыру (38 процентка) кебек хезмәтләргә дә сорау арткан. Кер үтүкләү (44 процентка), тәрәзә юу (33 процентка) кебек хезмәтләрне дә күбрәк сората башлаганнар.

Казандагы клининг оешмасы җитәкчесе Искәндәр Насыйров сүзләренә караганда, соңгы арада аларның эше, дөрестән дә, арткан. Моны, иң беренче чиратта, халыкның торган саен күбрәк уңайлыкка омтылуына бәйләп аңлата ул.

– Урын-җиреннән башлап, утырып йөргән машинасына кадәр уңайлы булырга тиеш аның. Чисталык мәсьәләсендә дә хәзер иң беренче чиратта шул таләп куела. Авыл кешесе дә үзен кадерли башлады. Соңгы елларда Казанда гына түгел, башкаладан 100 чакрым чамасы ераклыкта урнашкан Биектау, Балтач, Саба, Балык Бистәсе авылларына да хезмәт күрсәтәбез. Аннары шунысы да бар: туганлык җепләре елдан-ел зәгыйфьләнә барган, туган туган белән йөрешмәгән заманда яшибез. Шул сәбәпле хәзер күп кенә авылларда туганнар белән бергә җыелышып өмә ясап, өй юу йоласы да бетеп бара. Мөмкинлеге булган кеше бу эшне кеше чакыртып эшләтү ягын карый, – ди эшмәкәр.

Сорау артса да, хезмәтләренә бәяне арттырмаган алар. Ник дигәндә, бүген бу өлкәдә көндәшлек көчле.

– Ун ел элек клининг хезмәте белән яхшы ук акча эшләп була иде. Әмма хәзер мондый хезмәт күрсәтүче оешмалар саны артты, көндәшлек зур. Шуңа күрә хезмәткә бәя арттырудан мәгънә юк, – ди Искәндәр Насыйров.

Ялкаулык түгел

Хәзер хатын-кыз рәхәткә чыкты: ярымфабрикат сатып алып ашарга әзерли, кеше чакыртып өен җыештыра… Яшерен-батырын түгел, соңгы арада мондый фикерләрне еш ишетергә туры килә. Әмма гүзәл затлар үзләре бу сүзләр белән килешми.

Җырчы Гүзәлем фикеренчә, әлеге хезмәт – замана хатын-кызы өчен менә дигән коткару чарасы. «Без хәзер зур тизлекле тормышта яшибез. Хатын-кыз хәзер ир-ат белән бер дәрәҗәдә тормыш алып бара, бер үк дәрәҗәдә эшли. Хатын-кызның өй җыештыруга гомумән вакыты калмый. Бигрәк тә ул үз йорты белән яшәсә», – дип саный ул.

Җырчы үзе клининг хезмәтен ярты елга бер тапкыр – «генераль җыештыру» өчен чакыра икән.

– Яздан җәйгә кергәндә – бер килсәләр, Яңа елга кадәр өйне тагын бер кат чистартып китә алар. Ике катлы өйне берүзем берничек җыештырып бетерә алмыйм. Өмә ясап, өйне юып алырга туганнарым да Казанда яшәми. Шуңа күрә минем өчен клининг хезмәте – бик яхшы коткару чарасы. Гомумән, үз өе белән, зур өйдә яшәгән кешегә бик уңайлы ул, – ди Гүзәлем. – Шулай да клининг оешмасы белгечләре синең йортыңны да, кайсы җирдән, нәрсәне алып бетерергә кирәклеген дә аңлап бетермәскә мөмкин. Үз өеңне синнән дә яхшырак белүче юк. Дөрес, батарея араларын – пар генераторы, духовканы югары температура белән җылыта торган җиһаз ярдәмендә чистарталар. Менә аннан соңгы чисталыкка гади ысуллар ярдәмендә генә ирешеп булмый – анысы хак. Стена, түшәмнәрне дә махсус чара, чүпрәкләр белән юалар. Ә менә көзгеләрне, киштәләрне хуҗабикәнең үзеннән дә яхшырак чистартучы юк.

Балтач районының Бөрбаш авылында яшәүче блогер Альбина Фазлыева да бу хезмәтнең рәхәтен татып караган.

– Әбиләр, әниләр элек өй бүрәнәләрен кер сабыны һәм мунчала белән ышкып юган. Хәзер мичкә дә ягасы юк, көл тузаны да юк. Хәзер бу эшнең авырлыгы кимеде, ләкин эш мәйданы артты. Элеккеге кебек алты почмаклы өйләрдә генә яшәмибез хәзер. Шуңа күрә елга бер тапкыр мондый хезмәттән файдалану хатын-кыз өчен зур уңайлыклар тудыра дип уйлыйм. Уңай яклары бик күп. Бар эшне синең күз алдында, яңа төрле техника кулланып эшлиләр. Пар генераторы ярдәмендә агач стеналарны, торбаларны чистарттылар. Артларыннан искиткеч чисталык кала. Бу хезмәттән файдалануны ялкаулык дип кабул итәргә кирәкми. Хәзерге заманча тормышта бу эшнең ояты юк, – дип саный ул.

Килен эше

Казанда яшәүче Алсу Нәбиуллина фатирын чисталыкта тотуны берничә кат астарак яшәүче күршесенә ышанып тапшырган. Моның өчен ул аңа сәгатенә 250 сум акча түли икән.

– Бер юридик оешмада эшлим. Эшем бик тыгыз. Фатирдагы тузан, пычрак өчен баш катырырга хәлем дә, теләгем дә калмый. Шуңа моны кеше чакырып эшләтергә булдым. Безнең йортның «Ватсап»тагы төркемендә бер хатын-кыз шул эш сорап язган иде. Бездән берничә кат астарак яшәүче Гүзәл исемле ханым булып чыкты. Ике көнгә бер кичке якта кереп өй җыештыра. Тузан сөртү, идән юу, кер юдыру, кер үтүкләү – аның өстендә. Болар өчен сәгатенә 250 сум акча түлим. Ашарга пешерергә өлгермәсәм, тагын шуның кадәр акча өстим, – ди ул.

Буа районының Ташкичү авылында яшәүче фельдшер Рамилә Ибәтова да, кеше чакыртып, өй җыештыртуның ояты юк, дигән фикердә. Берничә ел элек үзе дә, күрше авылдан хатыннар чакырып, өй юдыра торган булган ул.

– Бер-ике ел элек күрше Чишмә авылыннан бер төркем хатын-кыз килеп өйне юып китте. Ул чакта дүрт хатын-кызга 500әр сум акча түләгән идем. Ике катлы йортның түшәменнән алып идәненә кадәр бөтен өеңне юып, тәрәзәләрне чистарып китүләре өчен чүп кенә бәя иде инде бу. Мөмкинлегең булса, файдаланырга кирәк. Хәзер инде бер кешегә 1000–1500 сум алалар. Шулай да безнең авылда бу хатыннарның хезмәте бик популяр. Ялгыз яшәүче әби-бабайларның оныклары шуларны чакыртып, өйләрен юдыртып ала. Соңгы елларда үземнең бу хезмәттән файдаланганым юк. Аллаһка шөкер, киленнәрем бар. Өйне өмә ясап юалар, – ди ул.

КАЗАНДА КЕШЕ ЧАКЫРТЫП ӨЙ ЭШЛӘРЕН БАШКАРТУ КҮПМЕГӘ ТӨШӘ?

Клининг оешмасы		«Бер сәгатькә ир» хезмәте	
хезмәт	бәясе	хезмәт	бәясе
Йорт/фатирны тулысынча җыештыру	1 квадрат метры/ 60–65 сум	җиһаз җыю	сәгате 300–350 сумнан башлана
келәм юу	1 квадрат метры – 165 сум	сантехник	350–500 сум
тәрәзә юу	1 катлы – 300 сум 2 катлы – 400 сум 3 катлы – 500 сум балкон – 1400 сум	савыт-саба юу машинасын урнаштырып, тоташтырып бирү	1500 сумнан башлана
йомшак җиһаз чистарту	урындык – 150 сум диван – 1500 сум матрас – 900 сум	стенага телевизор, киштә элеп бирү	150–200 сум
ремонттан соң җыештыру	Квадрат метры – 60–100 сум	электрик	600 сумнан башлана

Кадакны кем кага?

Өлешчә мобилизация игълан ителү белән Россиядә «Бер сәгатькә ир» хезмәтенә дә ихтыяҗ нык арткан. «Авито.Хезмәтләр» порталы аналитикларына ышансаң, андый эшкә чакыручылар 33 процентка күбәйгән. Соңгы арада бигрәк тә электрик, сантехник хезмәтләре популяр икән. Җиһаз җыеп бирү, ишек, ишеккә бик кую өчен «бер сәгатькә ир» чакыртучылар да шактый.

Татарстанда мондый «ир»ләрнең бер сәгатьлек хезмәте 390–450 сум арасында тирбәлә. Бу бәягә белгеч ир-атның тәҗрибәсе, башкарылган эшнең ни дәрәҗәдә катлаулы булуы да йогынты ясый. Әйтик, башкалада юыну бүлмәсенә смеситель кую – 690 сумнан, йорт җиһазы җыюның бер сәгате 300 сумнан башлана.

«Бер сәгатькә ир» хезмәтен башкаручы Айдар Гаффаров сүзләренә караганда, аларның хезмәтләренә сорау көз көне үк – өлешчә мобилизация игълан ителгәч арта башлаган. Сорау арткач, күрсәтелгән хезмәтнең бәясен дә арттырган ул.

– Хатын-кызлар, әбиләр вак-төяк йомыш белән дә мөрәҗәгать итә. Берәүләрнең түшәменә люстра эләргә кирәк, икенчеләре стенага киштә элүне, аш бүлмәсендәге урындыкны рәтләүне сорый. Яңа елдан бәяләрне дә бераз арттырырга туры килде. Моңа кадәр мин күрсәткән хезмәтләрнең бер сәгате 800 сум торса, хәзер 1100–1200 сумга төшә. Дөрес, кешесенә карап, бәяне төшергән вакытлар да күп. Әйтик, олы яшьтәге апаларга, әбиләргә еш кына ташлама ясыйм. Хәлләрәк кешеләрдән тиешле бәяне кайчак артыграк та алгалыйм, – ди әңгәмәдәшем.

Ил халкы «бер сәгатькә ир»ләрне, нигездә, бушлай игълан сайтларыннан эзли икән. «Авито» порталы белгечләре уздырган сораштыруда катнашучыларның 95 проценты мондый осталарны сайлаганда иң элек сайтта алар турындагы кайтавазларга игътибар итә икән. Респондентларның 51 проценты игъланда үзе күрсәткән хезмәтләр һәм аларның хаклары турында төгәл мәгълүмат калдырган кешеләргә өстенлек бирүен әйткән. Сораштыруда катнашучыларның тагын 22 проценты «бер сәгатькә ир»не игъландагы фотосына карап сайлый икән.

Динә ГЫЙЛАҖИЕВА

СИН НИНДИ – УЛ ШУНДЫЙ

Чит баланы үзеңнеке кебек яратып буламы? Була икән. «Без бергә» төбәк иҗтимагый оешмасының Казан бүлеге җитәкчесе Әлфия Самсонова шулай ди. Үз канаты астына өч ятимне сыендырган кеше ул. Аллаһы Тәгалә аңа сабый сөю бәхетен урау юллар аша биргән.

– Ятимнәрне тәрбиягә алырга теләүчеләр күп ул. Әмма алар белән уртак тел тапмаучылар да очрый. Сабыйны кире илтеп бирү – яхшы әйбер түгел. Ул аның күңелен яралый, кешегә булган ышанычын бетерә. Шуңа күрә алганчы уйларга, алгансың икән, ничек тә сабыйлар белән уртак тел табып яшәргә кирәк. Татарстанның 12 районында «Без бергә» оешмасы эшли. Ул нәкъ менә тәрбиягә бала алган әти-әниләргә ярдәм йөзеннән барлыкка килде, – ди Әлфия.

Башкалар турында сөйләшкәнче, үз сабыйлары хакында сүз башладым. Баксаң, беренче балаларын алып кайтканнарына 10 ел тулган икән инде.

– Әгәр баланы бер күрүдә ошатасың икән, аны үзеңнеке итеп яратып була. Үземә бала табу насыйп булмагач, бәлки, мин дөрес тә әйтмимдер. Ятимнәр йортына килеп керүгә, күзем кечкенә генә бер малайга төште. Безгә кайтканда улыма 2 яшь тулмаган иде әле. Ул да безгә тиз ияләште. Әни булу шундый ошады миңа, хисләрем ташып торды, – ди Әлфия.

Дөрес, барысы да җиңел генә бармый. Улларында неврологик яктан тайпылыш барлыгы ачыклана. Сабый биш яшендә генә сөйләшә башлый. Укуда да иптәшләреннән калыша. Беренче сыйныфны тәмамлагач, әнисе аны өйдә генә укытырга була. Бу вакытка үзе дә лаеклы ялга чыга. Өйдә утыра башлагач, күңеленә нидер җитми башлый аның. Ире белән киңәшләшә дә, берәр кечкенә кыз бала алып кайтырга кирәк, дигән уйга киләләр.

– Бер кызчык урынына ике зур кыз алып кайттык. Аларга ул чакта 6 һәм 9 яшь иде. Бертуганнар икән. Башта әниләре, аннан әтиләре үлеп киткән. Кызларны ерак туганнарына тәрбиягә бирәләр. Менә шунда башлана инде газаплы тормышлары. Кызлар авырлыкны күп күрәләр. Хәтта түтәлдән рөхсәтсез кыяр өзгән өчен дә җәфалыйлар аларны. Ярату дигәннең тамчысы да эләкми.Ниләр күргәннәрен сөйлисем дә килми инде хәзер. Хәтта искә төшерсәм дә читен. Әле дә кызларымның күңелләре боек. Олысы бик авырлык белән ияләшә, – ди Әлфия. – Ә менә улым белән беренче көннән үк уртак тел таптылар. Әйтерсең, гомер буе бергә яшәгәннәр. Шулкадәр тату үсәләр. Бергә уйныйлар. Ә безгә алар беренче көннән үк «әти», «әни» диделәр. Улыма карыйм да аның безгә эләгүенә сөенәм. Әгәр алмаган булсак, берәр интернатка җибәрерләр иде. Даими шөгыльләнүләр бушка китмәде, бер дигән егет булып үсеп килә. Эшкә батыр. Юкса кушып эшләтүче дә юк. Үзе шундый. Әтисе һәрчак янында йөртеп, хезмәт яратырга өйрәтте.

Әлфия белән яңадан кызларга әйләнеп кайтабыз.

– Мин алар белән гел сөйләшәм инде. Нәрсә кирәк, нәрсә ошамый, барысын да әйтегез, дим. Дәшмиләр. Күңелләрендә нидер бар. Шуңа да алар белән бик сак аралашам. Кителгән күңелләрен тагын ералаудан куркам. Мин аларны аңлыйм. Кечкенә генә булсалар да, нинди зур кайгы кичергән сабыйлар бит алар! Әтисез дә, әнисез дә калып кара әле син. Җитмәсә, тагын күпме кыенлык кичергәннәр. Өстәвенә кабат ятимнәр йортына илтеп тапшырганнар, – ди Әлфия.

Әнә шул кире кайтарулар, җәберләүләр булмасын өчен, алар «Без бергә» оешмасын оештырган да инде. Республикада аны Светлана Елакова җитәкли. Сүз уңаеннан, Татарстанда 7 меңгә якын гаилә тәрбиягә бала алып үстерә. «Без бергә» оешмасы 300дән артык гаилә белән эшли. Тәрбиягә бала алган әти-әниләр бергә җыелып сөйләшәләр, төрле чаралар уздыралар икән.

– Ата-анага да ярдәм кирәк. Бала алып кайтып яши башлагач, әллә нинди проблемалар баш калкыта. Әнә шул чакта ничек тә киңәш бирергә, туры юл күрсәтергә тырышабыз. Уйлап карагыз әле, ике төрле мохиттә яшәгән кешеләр очраша. Һәркем үзенчә тели. Менә шунда аңлашылмаучанлыклар да була инде. Кечкенә баланы әле үзеңә ияртергә була, ә менә характеры барлыкка килгәннәрне юк. Без бит яшүсмерләрнең нинди гаиләдә үскәнен, нәрсә кичергәнен белмибез. Үз әти-әнисе белән яшәп тә, кулына каләм тотып карамаган, тәмле ризык күрмәгән, кыйналып яшәүчеләр бар, – ди Әлфия.

Тәрбиягә алынган гаиләдә дә яклау тапмаса, аны ишетмәсәләр һәм күрмәсәләр, бала үз эченә бикләнә. Әлфия сөйләвенчә, мин начар, берәүгә дә кирәк түгелмен, дип уйлый башлый, кырыслана.

– Бу балалар белән алар телендә аңлашырга кирәк. Кимсетмик. Кеше баласын үстерү җиңел булмаганны белеп, бу эшкә алынабыз бит. Димәк, сабырлык кирәк. Тәрбияләсәң, һәр балага нидер кирә. Аларга тукып торырга кирәкми. Үзең күрсәт. Эшең, гамәлең, хәтта гадәтләреңне үзгәрт. Бала синнән күреп өйрәнә. Әйткәнне кабул итмәсә дә, күргәнне эшли ул, – ди Әлфия. – Һәрвакыт үзең үрнәк булырга кирәк. Үзеңдә булмаганны баладан сорап булмый.

МИНЗӘЛИЯ МИҢНЕБАЕВА:

«ЙӨГЕРЕП ЙӨРИСЕМ КИЛӘ»

Гомерең бетмәсә, яшисең икән! Чак кына үлемнән кала Минзәлия. Табиблар да озак яшәмәс дигән була. Өйдәге өч баласы, газиз әнисе хакына савыга ул. Әмма әлегә аякларына басып йөри алмый. Йөрер өчен ярдәм кирәк.

Үзган ел бөтен Казанны шаулаткан куркыныч вакыйгадан соң без, Минзәлиянең балалары белем алган мәктәп җитәкчелеге белән элемтәгә кереп, аңа ярдәм дә оештырган идек. Инде хәзер үзе белән сөйләшергә насыйп булды. Хәтерләсәгез, үзе эшләгән кибеткә килеп, элеккеге ире яралаган иде.

– Элеккеге ирем балаларны үзенә алып торгалый иде. Ул көнне дә авылга алып китәсе килде. Мин каршы килмәдем, әмма бер кызыбыз, кайтмыйм, диде. Аны-моны уйламадым, эшкә киттем. Әмма аннан инде үз аякларым белән кайтырга насыйп булмаган икән, – дип искә ала Минзәлия. – Умыртка баганасына һәм бөерләремә зыян килгән иде. 2 литрга якын каным аккан. 6 нчы хастаханәгә алып барганнарын хәтерлим. Әмма үземнең кыяфәтемне күргәч, аңсыз егылганмын. Төш булганмы, әллә башка нәрсәме, бер күренеш истән чыкмый. Янымда апак киемнәрдән күп кешеләр басып тора. Алар нидер эшли. Арада бик озын буйлысы да бар. Анысы карап кына тора. Шунда мин, үлдем, ахры, балаларым кайда икән, дим. Тар гына тишеккә төшеп барам. Шул чакта мине өскә күтәреп җибәрделәр. Табибның, йоклый гына күрмә, дигән сүзеннән аңга килдем.

Минзәлия бер атна буе авыр хәлдә ята. Аның бөтен эчке органнарын кузгаталар. Бөергә дә катлаулы операция ясала. Кая анда элемтәгә чыгу! Үз хәле хәл була. Авылда яшәүче әнисенә хәбәр килә: Минзәлия үлгән! Нишләргә дә белмәгән ана Казанга чыгып китә. Морглардан кызының мәетен эзли. Бөтен хастаханәне әйләнеп чыга. Таба алмагач, авылга кайтып китә. Өйгә керешкә, телефоны шалтырый. «Кызыгыз исән», – диләр. Эченә җылы кергән ана, оныкларын эзләп, тагын Казанга чыгып китә. Ә аларны балалар йортына илтеп тапшырырга өлгергән булалар инде. 75 яшьлек әбиләре оныкларын юллый башлый.

– Балаларым да мине үлгән дип белгән. Сабыйларымны «Дом малютки»га илткәннәр. Өчесе дә төн буе әни дип елап чыкканнар. Әнием эзләп тапканда аларны инде төркемнәргә бүлгән булалар. Аллаһы Тәгаләнең рәхмәте белән, әнием оныкларын 6 айга тәрбияләп торырга рөхсәт алган. Хәлем уңайлануга, яныма әнине керттеләр. Мин аның алдында башымны иям. Апам һәм әнием булмаса, нишләр идем икән... – ди Минзәлия.

Менә шул чакта күңеле тулып китте үзенең. Күпме күргән, моңарчы да әллә ничә кат үлемнән калган Минзәлиягә киредән тормышка кайту җиңел булмый. Авыр хәлләрен җиңеләйтер өчен психологлар ярдәме кирәк була үзенә. Балаларны тынычландыру өчен дә күп тырышырга туры килә.

– Газета аша миңа ярдәм кулы сузган һәр кешегә чиксез рәхмәтемне җиткерәм. Бик кыйммәтле 35 укол ясадылар. Барысын да изге күңелле кешеләр күчергән акчага алдылар. Балаларым укыган мәктәп коллективына, сезгә, мине белгән һәм белмәгәннәргә рәхмәт кенә укыйм. Минем бик тә атлап кына түгел, йөгереп йөрисем килә. Әлегә аяклар гына тыңлап бетерми. Арка миенә зыян килгән. Табиблар, ныклап йөри алыр өчен 2 ел вакыт кирәк, диләр. Башта арбада йөргәнемә сөендем. Хәзер исә тотынып атлавыма шатмын, – ди Минзәлия. – 6 нчы хастаханәгә эләгүем аркасында исән мин. Андагы табибларның ярдәмчеллеген күрсәгез иде. Шәфкать туташлары, санитаркаларга кадәр җаны-тәне белән гомерем өчен көрәште. Тән ярамны гына түгел, күңелне дәвалады алар. Бирешмим әле мин. «Әнием» дип торган өч балам бар. Әнием, туганнарым исән-сау. Мин күпләргә кирәк. Тикмәгә генә теге дөньядан кайтарып җибәрмәгәннәрдер инде.

Минзәлия Миңнебаевага ярдәм итәргә теләүчеләр өчен аның исемендәге Саклык банкы (Сбер) картасы 89046694321 телефон номерына беркетелгән.

Гөлгенә ШИҺАПОВА әзерләде

АЙДАР ҖАББАРОВ:

«РЕПЕТИЦИЯ – АРТИСТ БЕЛӘН РЕЖИССЕРНЫҢ МӘХӘББӘТ АҢЛАШУЫ УЛ»

Халык театрга нәрсә эзләп килә? Татар театры заманнан алдамы, арттамы? Режиссер тамашачының үзен тануын телиме? Болар хакында Камал театры режиссеры Айдар ҖАББАРОВ белән сөйләштек.

:: Бүген тамашачыга нәрсә җитми?
– Мин, төрле театрларга барып, спектакльләр карарга яратам. Махсус. Режиссерга, миңа калса, вакуумда калырга ярамый. Ул дөньяда театр өлкәсендә барган бөтен яңалыклар белән танышып барырга тиеш. Башкача ярамый. Әйтик, атна-ун көн элек Германиядә спектакльләр карап кайттым. Постдрама театрында актер уены мөһим түгел. Шуңа күп кенә спектакльдә беренче урында – техник мөмкинлекләр. Аны аттракцион дип әйтсәң була. Техник яктан шәп инде менә, ут тавыш дисеңме, ут мөмкинлекләреме – әмма бит ниндидер хис тумый. Ә хис кайчан туа? Кешенең икенче берәү белән мөнәсәбәтләре барлыкка килсә. Герой ниндидер тормыш киртәләрен уза алса. Җыеп әйткәндә, спектакль кеше турында булса. Монда ул юк. Россияне алсак, бигрәк тә Казанда, бездә – психология театры. Монда декорация булмаска да мөмкин, әмма диалоглар аркылы драма, кешенең фаҗигасе, җыеп әйткәндә, хисләре күренә һәм ул тамашачыны үзенә беректереп куя.

> Татарстан театр юнәлешендә соңгы 7–8 елда бик зур адымнар белән алга китте һәм, минемчә, бүген татар театрының тамашачысы мәгънәле, тирән спектакльләргә сусаган. Алар нәкъ менә эчтәлекле, мәгънәле спектакльләрне яратып карыйлар. Тамашачы өстән-өстән генә эшләнгән спектакльләргә шунда ук мөнәсәбәтен белдерә. Ә бит кайчан гына, безнең тамашачыга комедия кирәк, дип әйтә идек.

:: Тамашачы сине аңлап бетердеме инде? "Агыла да болыт агыла" (Хәсән Туфан, Туфан Миңнуллин) спектакле белән Айдар Җаббаров дигән режиссер барлыгын белдердең, "Тормышмы бу?" (Гаяз Исхакый) белән яраттырдың, «Санаулы кичләр» (Володин) белән аз гына үзеңнән читләштердең. Хәзер сез тамашачы белән нинди мөнәсәбәттә?
– Миңа менә шундый дулкын-дулкын кичерешләр ошый. Хәтта, аңламасын иде мине тамашачы, дип телим. «Ә-ә, бу Айдар икән, аның алымнары әллә кайдан беленә», – диләр икән, бу, минемчә, начар. Төрле булырга кирәк, бу бит Айдар түгел, ул болай эшли алмас, дип шаккатсыннар иде. Ул чакта мин ихлас шатланыр идем. Бер спектакльне ярата, икенчесен авыр кабул итәргә мөмкин – бу табигый. Димәк, мин кабатланмаганмын. Эшне башлап җибәргәндә, кабатланмаска, дигән максат куям. Текстка алынганда, беренче сызымнарын сызганда да, «Бу алымны кулланганым булмадымы?» дигән сорау куям.


Илдар Мөхәммәтҗанов

Әгәр ул юл үтелгән икән, икенчесен эзлим. Бер юлдан бару ул – иң җиңеле. Син аны эшли беләсең, аны халык та кабул иткән. Ә яңа юл салу авыр һәм ахырда ничек килеп чыгасын син үзең дә белмисең. Шуның белән кызыклы да инде ул.

:: Айдар, син бит – актер булып башлаган кеше, режиссер булу теләге кайчан туды?
– Актерлык белән кызыксыну Чаллыда мәктәптә укыганда ук башланды. Чаллы театры спектакльләрен карый идем. Аннары театр училищесында Фәрит абый (Фәрит Бикчәнтәев – Камал театрының баш режиссеры. – **Ред.**) курсына укырга кердем. Барысы да аның фатихасыннан башланды. «Син режиссурага укырга керергә тиеш», – диде ул миңа. Бик озак үпкәләп тә йөрдем әле, чөнки иң зур хыялларымның берсе Камал театрында артист булу иде. Фәрит абый режиссурага укырга дигәч, димәк, ул миндә актерлыкны күрми дип бик борчылган идем.

:: Ә син – яхшы артистмы соң?
– Нормальный инде. ГИТИСта спектакльләр уйнадык, Аллага шөкер. Миңа сәхнәдә булу ошый.

:: Татар классикасы, бигрәк тә Исхакый синең өчен аеруча әһәмиятле кебек. Исхакый әсәрен Камалда да, Әлмәт театрында да сәхнәләштергәнгә әйтәм.
– Һәрбер режиссерның үз авторлары була. Син ул авторны тоемлыйсың, аның энергиясе белән тоташасың кебек. Әйтик, Горький минем автор түгел, Чехов исә минеке. Кемгәдер, киресенчә, Чехов туры килми. Исхакыйны аңлыйм мин аны. Тоям. Аны сүз белән аңлатып та булмый.

:: Ә менә Еники дөньясы ничек бирелде? Бу язучыны тулаем аңладым дип әйтә аласыңмы?
– Еникинең дөньясына кереп китә алдым. Аңладым дип әйтә алам. Аңламасаң, спектакль куеп та булмый инде ул.

:: Ни өчен «Рәшә» төрле бәхәс-фикер алышулар тудырды?
– Их, шул Рәшидәне Зөфәр белән бергә калдырса, дип уйлаганнардыр. Кызганыч, тормышта бар да ал да гөл була алмый шул.

:: Бәлки, Еники әсәре финалына рус классикасы традицияләре кушылуны кабул итмәгәннәрдер.
– Бәлкем, шулайдыр да. Төрле фикер булды инде.

…Мин фәкать финалны гына үзгәрттем. Ә калганы – Еникичә. Беренче төндә, Островский урамындагы фатирда очрашулар да әсәрдә язылган. Мин дә бик кызганам аны. Гүзәл белән репетициядә, Рәшидә монологларын укыганда, ул елый, аңа мин иярәм. Аның героинясының тормышы бик авыр, бик катлаулы. Беренче иренең ташлап китүе, татар сәнгатен күтәрәм дип биредә калуы, тик монда беркемгә дә кирәк булмавы… Нәтиҗәдә менә шундый спектакль туды.

:: Еникинең тагын берәр әсәренә алыныр идеңме?
– Андый ният бар. «Рәшә»дә дә бит ике әсәре файдаланылды. Беренчесе классик формада, күпләр теләгәнчә, икенчесе… Азрак тамашачыны котыртып алдык.

:: Мәскәү театрларында спектакль чыгару җиңелрәкме, татар театрларындамы?
– Минем өчен андый бүленеш юк. Яңа урында, яңа кешеләр белән эшләү, аларның үзләре дә белмәгән мөмкинлекләрен ачу кызык.

:: Яшь режиссерга буйсынырга теләмәүчеләр дә табыла торгандыр?
– Бигрәк тә беренче елларда Мәскәүдә андый хәл белән очраштым. Тыңлатуның төрле чаралары бар, прәннек кулланырга да мөмкин, камчы да. Мин беркайчан да камчы кулланмадым. Минем өчен артист белән режиссер – иң бәхетле һөнәр ияләре. Алар яраткан эшләре белән шөгыльләнә, шуның өчен акча да ала.

Шуңа күрә репетиция (ә ул бик озак вакытка, әйтик, 3–4 айга сузыла) рәхәт узарга тиеш. Репетиция – артист белән режиссерның мәхәббәт аңлашуы ул. Ягъни яратып эшләргә кирәк. Анда берәүдә дә начар энергия, тискәре караш булмаска тиеш. Андый нәрсә сизелә икән, мин үз эчемә бикләнәм. Миннән шундый караш булса, артист йомылыр иде. Андый очракта репетицияне туктатырга гына кала.

Кайчак ничек итсәң дә, репетиция бармый. Андый чакта туктыйбыз, чәй эчәбез. Сүз ара сүз китеп, яңадан спектакльгә кайтабыз. Педагог Юрий Бутусов, «Сатирикон»да беренче спектакль чыгарганда, артистларны кафега чакырган. Шунда бер яшь артист, түземлеге төкәнеп: «Безнең репетиция кайчан башлана инде?» – дип сораган. Юрий Николаевич: «Ул бара инде», – дип җавап биргән. Репетициядә үзара аңлашу – беренче урында. Менә шушы нәрсә булмаса, актер – режиссерны, режиссер актерны кабул итмәячәк. Актерның режиссер әйткән идея белән кызыксынып китүе кирәк, шулай булганда, эш бара. Әйткәнемчә, Мәскәүдә 3–4 мәртәбә булды андый хәл. Репетиция башланып бер-ике ай узгач, баш рольне башкаручы тәртәгә тибә башлый. Андый очракта уртага салып сөйләшергә кирәк. Әгәр инде синең героең: «Бу минем материал түгел», – дисә яки синең нәрсә теләгәнеңне аңламавын әйтсә, кул кысышып, матур гына аерылышырга кирәк. Мин бәхәс яклы түгел. Ләкин актерны никадәр тизрәк алмаштырсаң, шулкадәр яхшырак.

:: Өлкән буын актерлар белән яшьләрнең театрны кузгаллавы, гомумән, дөньяны кузгаллавы да аерыла. Әйтик, Равил Шәрәфи, хәзер яшь чагым булса, актер һөнәрен сайламас идем, дип белдерде. Ул – актер театрында эшләгән кеше. Хәзер – режиссер театры. Аларның аермасы зурмы?
– Әйе, хәзер күбрәк режиссерга йөриләр. Ләкин кайсыбер театрларда актерны беренче планга чыгару да бар. Ул афишаларда да күренә. Әйтик, Безруков катнашында фәлән спектакль сезнең шәһәргә килә, дип язылган була. Миңа исә башка юнәлештәге театр ошый. Додин театры, мәсәлән. Аның коллективында Елизавета Боярская, Сергей Курышев, Данила Козловский, Ксения Раппопорт кебек легендага әверелгән артистлар эшли. Әм-

Блиц-сораштыру

– Театрмы, киномы?
– Кино дөньясын белмәгәч һәм аның белән кызыксынгач, кино дип җавап бирергә була. Җавап миңа билгеле булмаган дөнья булганга гына кино файдасына.
– Соңгы укыган әсәрең нинди?
– Евгений Водолазкинның «Чагин» романы.
– Иң рәхәт ял кайда?
– Башны ял иттерә торган урыннарда. Ул – мунча керү һәм балык тотарга бару. Ә гомумән алганда, сәяхәт итәргә яратам.
– Кайчан өйләнәсең инде?
– Яраткан кызым барлыкка килү белән.
– Иң зур теләгең?
– Дөньялар тыныч булсын.

ма Додин афишада спектакль исемен һәм театрны яздыра. Шәһәр буенча беркайчан да Козловский, Боярская сурәтләре булган афишаларны элмиләр. Миңа калса, бу дөрес.

:: Җаббарова йөрибез, дисәләр дөресрәк, алайса?
– Белмим, ишеткәнем юк.

:: Проза әсәрләренә өстенлек бирәсең кебек, сәбәбе нәрсәдә?
– Заманча драматургиядә үземә якын пьесалар тапмыйм. Проза белән эшләүдән исә ләззәт алам. Текстны сәхнә әсәренә әверелдерү миңа энергия бирә. Әзер текст белән эшләүгә караганда эзләнү кызыграк.

:: Үз драматургың барлыкка килмәдеме әле?
– Юк шул. Әмма андый тандем бик кирәк.

:: «Көл» спектаклендәге теманы тамашачы бик зарыгып көткән икән, ниһаять, театр үз сүзен әйтте дип, бик яратып, йөриләр. Бу постановка әле дә бара, димәк, цензура әле синең әсәреңдәгечә бөтен фикерне дә туракламый. Хәзерге заман турында тагын нинди спектакль куяр идең?
– «Көл», кызганыч, безнең тормышыбызга бик якын булып чыкты. Әйдәгез, ачыктан-ачык сөйләшик әле. Спектакльнең кайсы җирлектә һәм нинди вакытта чыгуы әһәмиятле. Мин бик күп йөрим һәм кайсы театрда нинди хәлләр икәнен бик яхшы чамалыйм. Татарстанда цензура сизелми, башка җирләрдә сизелә. Яшерен-батырын түгел, башта үзем дә аны болай озак барыр дип уйламадым. Әмма әлеге спектакльне чыгарганда ярдәм зур булды. Теләктәшлек булмаганда, «Көл» булмас иде. Аны цензура туракламады, үземнең эчке цензурам гына кайбер өлешләрен кыскарттырды. Әгәр тыелган икәнен белә торып та кайбер җырларны калдырган булсам, бу инде хайп булыр иде. Мин андый нәрсәне яратмыйм. «Көл» үз урынында, үз вакытында чыкты. Тик шунысы да бар: аңа бөтен тамашачы да әзер түгел. Аның үз тамашачысы бар һәм алар күп түгел. Гомумән, һәр спектакльнең үз тамашачысы бар. Кемдер драма ярата, кемдер уйларга бирелмичә ял итеп кайтырга да килә. Андый тамашачыны да онытмаска кирәк. Бу җәһәттән театрлар күбрәк һәм төрлерәк булган саен, яхшырак. Алар бит тамашачы тәрбияли. Фикерле, төпле кешеләрне… Нинди спектакль дигәндә, бер идея бар, әмма әйтми торыйм әле. Алдан кычкыру күп очракта яхшыга илтми.

:: Безнең киләчәк өметлеме?
– Миңа калса, өмет бар.

Әңгәмәдәш – Гөлинә ГЫЙМАДОВА

Шигърият

Рөстәм САФИН

ОЧРАШУ…

Әйдә утыр, бер сөйләшик,
Юк, тутырма, чак кына!
Тамчысы да ялкын салыр,
Җан тилмерткән чаткыга.

Минем хәлем? Ярый инде,
Дөнья уйлап, җан теләм!
Бер көйләгән көйгә яшим,
Бер җайлаган җай белән.

Әйе, шулай, каршылыкта,
Эчке дөньям һаман шул.
Соңгы тапкыр үпкәләдең,
Син ак дигән кара шул.

Үзең ничек? Уйлатамы
Күзгә күргән мизгелләр?
Кабат үрнәк диярсеңме
Гөнаһ юган «изгеләр»?

Вәгазь уку газабыннан,
Яшьләр сүгеп көн саен,
Көч-хәл белән сөрәсеңме
Буразнаның иң саен?

Ничек анда төсле тартма,
Күп сөйлиме ялганны?
Чит фикерне салма, зинһар,
Әйт үзеңнән алганны.

Миңа шундый сорау сиңа:
– Халык күнсә тынлыкка,
Үз юлында коллык күреп,
Ник дан җырлый коллыкка?

Аңламадың? Хәерлерәк!
Калдыр халык кирләрен.
Әйдә сөйлә, гөнаһ юып,
Дөрес яшәү серләрен.

ТУГАН ЙӨРТКА ОҖМАХ ХАТЫ…

Хәзер инде минсез яшәп,
Гомер зарын сулаганда,
Тагын бер көн кичкә китеп,
Күләгәсен аламы анда?

Офык шулай кызарамы,
Кояш йотып оялудан?
Алданамы тәрәзәләр,
Мин бар, диеп ут алудан?

Чабылмагач капка төбе,
Юкка саный микән үзен?
Ничек анда каршы урман,
Күрәме әле тәрәз күзең?

Җәрәхәттер тәнеңдә дә,
Черек агач, авыр ташлар…
Кара әле мәчеткә дә,
Күренәме авылдашлар?

Әллә инде иң соңгысы,
Санаганга китәр көнен,
Сирәк җан да калмадымы,
Ишетергә татар телен?

АВЫЛЫМА!

Булырсыңмы? Бер кайтырмын,
Бу заманда димим, күпкә соң!
Насыйп булса, яланаяк,
Сүзсез ачып оҗмах капкасын.

Кайтырмын мин таныш юлдан,
Ялыктырыр сагынып тик яту.
Кайтырмын мин үзем теләп,
Сабыйларча булмас ул кайту.

Каеннардан юл сорармын,
Адашырлык булса хисләрем.
Кайтырмын мин май аенда,
Кич тараткач шомырт исләрен.

Син, әлбәттә, мине танырсың,
Капласа да гасыр тузаны.
Мин дә сине, туган нигезнең
Югалса да күптән эзаны.

Менә шунда яшь йотармын,
Чал башымны мең кат иеп.
Я әйт миңа исән чакта:
«Мин булырмын, син кайт», – диеп!

< Ахыры. Башы 27 гыйнвар, 3 февраль, 3 март саннарында

АСИЯ ЮНЫСОВА

МАДАМ БОВАРИ

Ничек якынаерга икән соң бу соры күзләр иясе белән? Уйлый торгач, Мәүлия бер хәйлә тапты. Кондуктор белән дуслашырга кирәк. Көн дә шушы трамвайга утыра торган хатынны кондуктор апа күптән абайлаган иде инде. Мәүлия үзе башлап эндәшкәч, ачылып сөйләшеп китте. Мәүлиягә юньрәк бәягә айлык юл йөрү билеты тәкъдим итте. Алды Мәүлия, билеты болай да бар иде югыйсә. Үз чиратында яхшылык кылып, гел бушлайга газеталар тәкъдим итте. Эшләгән җирендә аз-маз сыйфаты киткән газеталарны бракка чыгаралар. Укымаслык түгел. Көн дә күчтәнәч калдырып төшә торган чибәр хатынны трамвай йөртүче дә таный башлады. Ерактa Мәүлия күренсә, кузгалмыйрак көтеп тора. Күп вакыт Мәүлия үзе көтә.

Хәзер инде Мәүлиянең төнге хыял дөньясына шушы басынкы кыяфәтле ир керә. Хыялында Мәүлия аны тәрбияли, авырса, терелтә. Аркасын сылый, эшенә алып бару өчен термоска кайнар аш сала. Ризыкны тәмиз, әй лә, кершәндәй ак сөлгегә төрә. Трамвай деполары ирнең моңача аксыл яңакларына төс кергәнгә гаҗәпләнәләр. Сораштыралар. «Әллә кайчан өйләнәсең калган!» – дигән булалар. Болар барысы да – хыялда. Чынбарлыкта исә Мәүлия трамвай йөртүче кабинасына карап-карап алудан уза алмый. Кондуктор хатын белән дуслашып беттеләр инде. Шул рәвешле гыйшык тотып йөрүенә өч айлап узды бугай. Алга китеш юк.

Отпускыда авылында булып килде. Трамвай йөртүче анда да исеннән чыкмады. Ялдан соң беренче көн эшкә барышлы сары трамвайны тагын озак көтәсе булды. Көтмәс тә иде. Өметләнеп бу көтүләрдән башка дөньясы бигрәкләр бушап кала шул. Ниткән заман бу? Мәүлия кебек кырыкка җиткән хатынга түгел, япь-яшь кызларга кияү юк. Кайсы эчкече, кайсы наркоман, кайсы асылына, кайсы авариядә һәлак була, кайсы армиядән имгәнеп кайта, кайсы зәңгәр – кемне яратырга, кем белән оя корырга, хыялдагы матур кызны кемнән табарга? Хәер, бала табып үстерергә вакыты калмады инде хәзер Мәүлиянең. Ипле, төпле, тәмле сүзле бер иптәш табып керсә картлыгына, бәлки, бәхет шул булыр иде. Укымышлы малае Төркияне яратты. Кунакка гына кайтып йөрер кебек.

Килде трамвай. Кондуктор хатын гына түгел, трамвай йөртүче ир дә ачылып каршы алдылар аны. Мәүлиянең инде дус хатынга әйләнгән кондукторга авыл күчтәнәче бар иде. Тегесе, җире-күге белән сөенеп, рәхмәт әйтте. Пассажирларын да онытып, хәлләрен сөйли башлады. Мәүлиянең сүзне үз уңаенарак борасы килә:

– Ниме соң, болай сине эштән аерганга трамвай йөртүче сукранмыймы? Кайсы чакны көтеп тә аласыз…

– И-и, исең китмәсен. Ачуланмый да, сукранмый да. Сабыр холыклы адәм ул. Егерме ел торабыз. Ирем ул минем…

Кондуктор тагын күпме сөйләгәндер, Мәүлия анысын ишетмәде. Башына кирпеч кебек орган хәбәрдән ул аңгыраеп калган иде. «Базарга керәсем бар», – дип, тиз генә трамвайдан төшеп калды. Ничә айлар бәллүр савыттай кадерләгән хыялы тагын чәлпәрәмә килде. Үзенә кирәксез тукталышта ул шундый озак басып торды. Аннан кинәт кенә башына тапкыр уй килде: «Карале, бу кондуктор юри генә әйтмәдеме икән? Ул ир бит аңардан шактый яшь күренә». Икенче трамвайны көтеп алып, утыргач, кыенсынып-нитеп тормыйча гына сорады да куйды: «Ундүртенче маршруттагы 417 нче трамвайдагы бригада ир белән хатынмы, түгелме?» Әйе икән…

Шушы кирәкмәгән яңалыкны төяп, Мәүлия әкрен генә үзен беркем көтмәгән өенә кайтты. Ике фатирга уртак ишекне ачып кергәч, үз ишегенең тоткасына кыстырылган чәчәк бәйләмен күреп, сискәнеп китте. Әллә тагын Рахман килгәнме? Ишеккә тагын нидер сөялгән. Сәгать! Сәгать тартмасына язу кисәге кыстырылган. «Туган көнең белән тәбрик итәм, Әүлия! Озак эшлисең икән. Сәгать алтыларда кабат әйләнермен. Насыйп булса, күрешербез.

Мин».

Язуы Рахманныкы түгел. Кем булыр бу? Бүген Мәүлиянең туган көне икәнен дә белә бу кеше. Кырык яшьне билгеләргә ярамый дигәнгә ышанып, махсус «оныткан» иде Мәүлия бу көнне. Трамвайда ишеткән хәбәр дә кырык яшьнең бәхетсез яшь икәнен раслаган иде. Ә монда… бүләк. Ә монда… әйләнеп килүне вәгъдә итәләр. Кем булыр бу? Әүлия – Мәүлиянең мәктәптәге кушаматы. Димәк, бу кеше аны мәктәптән үк белә!

Мәүлия бәхетле минутлар, сәгатьләр, тәүлекләр санаенсы сәгатьне өйгә алып керде.

КОТЛЫЙБЫЗ!

60 тапкыр бергә җәйләр килгән,
60 тапкыр салкын кышлары.
60 тапкыр яз җылысын тоеп,
Җимеш биргән алтын көзләре.

Моннан **60 ел** элек, 1963 елның **12 мартында** безнең әти – **ӘБҖӘЛИЛОВ Баязит Нурми улы** Буа районы Яңа Тинчәле авылының уңган, чибәр, акыллы **Зөбәрҗәт Таһир кызын** гомерлек юлдашы итеп алып кайта. Нәкъ менә шул көнне аларга күктә никах укылган.

Кадерле әти һәм әни! Исәлекле гомер бәйрәмегездә – гәүһәр туегызда йөрәк түребездән чыккан иң изге, иң ихлас теләкләребезне барлык балаларыгыздан, килен-кияүләрегездән, оныкларыгыздан кабул итегезче! Дөньяның бар матурлыгын, кояш нурларының иң җылысын, гомерләрнең озынын, бәхетнең чиксезен, дөньяның бар шатлыгын пар канатлы булып, йортыбызның нуры булып яшәгез дә яшәгез әле! Рәхмәт сезгә, безнең кадерлеләребез! Без сезнең алдыгызда баш иябез, киләчәктә дә тормышыбызның яме булып, йортыбызның учагын сүндермичә, тазалыкта, саулыкта, икегез дә тигез пар канатлы булып, барлык балаларыгызның игелеген күреп, куанычларына сөенеп, шатлыклы хәбәрләрен генә ишетеп яшәргә язсын! Олы ихтирам белән, Буада яшәүче улыгыз **Рафаэль**, киленегез **Эльвира**. Бу теләкләргә кызларыгыз **Мөнәвәрә, Руфина**, кияүләрегез **Радик, Илфат, барлык оныкларыгыз** да кушыла.

Кем син?

- **Юзер** – интернет кулланучы.
- **Ламер** – компьютерларда өйрәнчек.
- **Хакер** – компьютер системаларын ватучы.
- **Лузер** – уңышсызлыкка таручы.
- **Фрилансер** – читтән торып эшләүче.
- **Блогер** – социаль челтәрдә актив язучы.
- **Геймер** – компьютер уены уйнаучы.

Сканворд җаваплары

Горизонталь: Раштуа, ТНВ, Дамир, АиФ, Киа, УЗИ, Барда, ян, орлык, фал, китә, Сафа, легионер, Алтай, рак, Нива, матди, Сая, укчы, камка, ар, Смәел, Фирая, касә, Күәм, ил, Кабул, Рената, нидер, норит, лимонад, йомгак, артикул.

Вертикаль: Баламишкин, Али, Рәгать, сәке, афоризм, Радик, ана, Лэйна, иялек, кемани, шампан, сал, Мамут, нам, Уно, утрау, ияк, Клондайк, Ан, Изотов, Ра, Вафирә, Фәридә, ял, Симет, ыслау, кат, Азат, фа, чая, айгыр, пар.

Сәхифәне Данил СӘФӘРОВ әзерләде

Беләсең килсә...

1 Лилия Муллагалиеваның ничә баласы бар?
а) 3;
б) 4;
в) 5.

2 Төньяк Кореяның дәүләт идеологиясе ничек атала?
а) Чучвара;
б) Чучхе;
в) Чурчхела.

3 Танылган автомобиль маркасына нигез салган Поршеның исеме ничек булган?
а) Федерико;
б) Флорид;
в) Фердинанд.

4 «Мөкәммәл» сүзе нәрсәне аңлата?
а) камил, житеш;
б) тиз, житез;
в) горур, данлы.

Җаваплар: 1. б); 2. б); 3. в); 4. а).

Баш мөхәррирнең беренче урынбасары – ХӨСНУЛЛИН Илнар Хәлил улы

Газетаны оештыручылар:
ТАТАРСТАН ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ, МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ, РЕДАКЦИЯНЕҢ ХЕЗМӘТ КОЛЛЕКТИВЫ

Газета Татарстан Республикасы Информация һәм матбугат министрлыгында 1995 елның 21 июнендә теркәлгән.

Теркәү таныклыгының номеры – 430.
Газета матбугат чараларының үзәк каталогына кертелгән.

Индекс П2435
Тираж – 15281 данә

Газетага сертификат бирелде
Заказ 233

РЕДАКЦИЯ ҺӘМ НӘШЕР АДРЕСЫ

420097, Казан, Академия ур., 2 й.
«Ватаным Татарстан» газетасы редакциясе.

www.vatantat.ru

info@vatantat.ru, vatantat@list.ru, vtreklama@mail.ru

89179270040

Индекс П2409 (гадәти сан – атнага дүрт тапкыр чыга)
П2448 (гадәти сан, пенсионерлар өчен)
П2449 (гадәти сан, оешмалар өчен)
П2435 (җомга саны)

ТЕЛЕФОННАР

222-09-70 – кабул итү бүлмәсе
222-09-67 – баш мөхәррирнең беренче урынбасары
222-09-73, 222-09-69, 222-09-65 – баш мөхәррир урынбасарлары
222-09-68 – авыл хуҗалыгы, фән һәм мәгариф
222-09-67 – дин, сәламәтлек
222-09-64 – әдәбият, сайт
222-09-66 – сәясәт, тәрҗемә, оператор, хатлар һәм социаль мәсьәләләр
222-09-65 – реклама бүлеге
222-09-72 – бухгалтерия
222-09-73 – компьютер үзәге
221-18-99 – газета килмәсә яки соңарып килсә

Оригинал макет **Jahat™** программалар пакеты ярдәмендә әзерләнде. Мәкалә авторларының фикерләре редакция фикере белән туры килмәскә мөмкин. Хатлар, кульъязмалар, рәсемнәр рецензияләнми һәм кире кайтарылмый.
R тамгасы куелган язмалар реклама буларак тәкъдим ителә.
N тамгасы куелган язмалар килешү нигезендә басыла.

Күчереп бастыру өчен редакциядән язмача рөхсәт алу шарт.
График буенча бу санга 20 сәгатьтә кул куелырга тиеш. Кул куелды – 20 сәгатьтә.

Ваклап сату бәясе килешү буенча.

Газета «ТАТМЕДИА» АҖ филиалы «Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексында басылып чыкты **(420066, Казан шәһәре, Декабристлар ур., 2й.).**

16+